وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№4 (237). АПРЕЛЬ – 2015 / ҖӘМӘДИӘЛАХЫР-РӘҖӘП – 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!



2 бит

## Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН Европада куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек оешмасы утырышында катнашты



7 бит

## 100 ел элек татар матбугаты нәрсә турында язган?



14 бит

## Җәннәттә авырга узу, бала табу буламы?



2 бит

## Татарстан мөфтие урынбасары Кырымга сәфәр кылды



15 бит

## Сүрия, Ливия, Йәмән: хәлләре шактый яман

*"ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ" газетасын өйгә дә яздырып алырга була. Почта бүлекчәләренә мөрәҗәгать итегез. Индекс –*



**16046**

# Мөхтәрәм Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары!

***Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!***

***Әссәләәмугаләйкүм үә рахмәтуллааһи үә бәракәәтүһ!***

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән сезне Җиңү бәйрәме белән котлыйм!

Җитмеш ел элек әби-бабаларыбыз каһарманлык күрсәтеп, вәхшилекне, кансызлыкны җиңгәннәр, Ватаныбызны, дөньяны фашизмнан коткарып калганнар. Һәм Аллаһы Тәгалә аларга җиңү бүләк иткән. Җиңү җиңел бирелмәгән, әмма җиңү бәрабәренә бүгенге буын тыныч тормышта яши.

Бик кызганыч, Бөек Ватан сугышы ветераннарының сафы елдан-ел сирәгәя бара. Шулай да алар турындагы истәлекләр, сугышта һәлак булучыларның батырлыклары турындагы хатирәләр гасырлар буена сакланыр. Халык җиңү бүләк итүчеләрнең каһарманлыгын һәм алар үткән куркыныч сугыш көннәрен истән чыгармас.

Без Аллаһы Тәгаләдән бу сынауларның башка беркайчан да кабатланмавын сорыйбыз. Аллаһы Тәгалә илебезгә бәхет һәм бәракәт насыйп итеп, Үзенең рәхим-шәфкатеннән ташламаса иде! Һәркайсыбыз җимерүгә, зыян салуга түгел, төзүгә һәм мәрхәмәтлелеккә, яхшылыкка омтылса иде. Бары шулай итеп кенә бу тормышта гармониягә ирешергә мөмкин.

Ихтирам белән

***Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН.***

# Татарстан мөфтие урынбасары Кырымга сәфәр кылды

**Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин Кырым Республикасы Бакчасарай районына эшлекле сәфәр кылды. Сәфәр кысаларында ул Кырым мөфтие Хаҗи Әмирали Аблаев белән очрашты.**

Эчтәлекле әңгәмәдә сүз ике дини оешма арасында хезмәттәшлекне ныгыту турында барды. Бакчасарайдагы мәчетне төзекләндерүдә ярдәм итү мәсьәләсе буенча да фикер алышу булды. Мөфти Хаҗи Әмирали Аблаев Татарстан кунагын бирердәге мөфтиятнең эшчәнлеге белән таныштырды. Рөстәм хәзрәт Хәйруллин Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламнәрен җиткереп, Кырым мөфтиятенә төрле өлкәләрдә ярдәм итәргә әзер булуларын белдерде. Очрашу ахырында Рөстәм хәзрәт ТР мөфтие исеменнән истәлекле бүләк тапшырды.

Кырымнан кайткач, Рөстәм хәзрәт сәфәрдән алган тәэсирләрен газета укучылар белән дә уртаклашты:

- Безнең Татарстан мөфтияте ярдәм итәргә алынган гыйбадәтханә Бакчасарайның 6 нчы микрорайонында урнашкан, бер манаралы, 300 кешелек җыйнак кына бер мәчет икән. Мәхәллә халкы да, аксакаллар да җылы каршы алдылар, килүебезгә бик шатландылар. "Без сезне инде күптән көтәбез, нишләп шулай озак килми тордыгыз? Кавказ мөселманнары әнә еш килә. Ә безнең сезнең белән аралашып яшисебез килә, чөнки тарихыбыз уртак, мәзһәбебез, телләребез бер", - дигән үтенечләрен җиткерделәр.

Тагын бер теләкләре бар - алар шул мәчеткә Казан татарыннан булган имамның килүен көтәләр. Бакчасарай хакимияте башлыгы, кулдан килгәнчә, ярдәм итәрбез, баштагы вакытларда торырга урын да табарбыз, дип ышандырды. Без, тагын нинди ярдәм күрсәтик соң, дип сорагач, мәхәллә картлары, мәчеттә салкын, түшәмнәрен җылытасы иде, аннары тәһарәтханәдә җылы су юк, шуны ясап булмас микән, диделәр.

Сәфәребез кысаларында шулай ук Татарстан Президентының Кырымдагы даими вәкиле Руслан Шаяхмәтов белән дә очраштык. Бакчасарайдагы иске мәдрәсәләрне, хан мәчетен карадык, анысы Хан сарае янәшәсендә генә икән. Элек кырымтатар ханнарының резиденциясе булган Хан сарае - дөньякүләм әһәмияттәге тарихи-архитектура, мәдәният һәйкәле булып санала. Биредә кырымтатарларның тарихи, мәдәният һәм сәнгать музее урнашкан. Музей директорының Казанда булганы бар икән, бик бирелеп Казан, Татарстан турындагы истәлекләрен яңартты. Бездәге тарихи объектларның торгызылуын, тәртипкә китерелүен хуплап, сокланып сөйләде ул. Кызганычка, Бакчасарайда, Кырымда бу юнәлештә әлегә берни дә эшләнми. Кырымтатарларның шундый бай мирасын сакларга Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәмен салсын.

Тарихи язмаларга караганда, ярымутрауга ислам динен Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сахабәләре алып килгән. Газы-Мансур дәрвишләр зиратында ерак җирләрдән ислам динен таратырга килгән сахәбәләр җирләнгән, без шул каберлекләрне дә карап чыктык. Кырымтатарларының бу мөкатдәс җирләрне дә тәртипкә китерергә дигән теләкләре бар икән, моны бер бай татарыбыз үз өстенә алып, мөфти хәзрәткә вәгъдә бирде. Сүз уңаеннан әйтеп үтим әле, шушы саваплы эшкә кушылырга теләүчеләр булса, Татарстан Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать итсеннәр иде, ярдәмнең артыгы юк... Россиядә беренчеләрдән булып без башлап җибәргән яңалыкларны тормышка ашыруда - уку-укыту стандартлары кертү, яңа дәреслекләр чыгару, мәдрәсәләрен Россия законнары буенча теркәтүдә дә кырымтатарларга ярдәм кирәк булачак. Бу юнәлештә ике мөфтият арасында инде эш бара. Тиздән Казанда ислам мәгарифе мәсьәләләре буенча Россия мәдрәсәләре директорларының җыелышы булачак. Анда кырымтатарлар да чакырулы.





# Камил хәзрәт Сәмигуллин Европада куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек оешмасы утырышында катнашты

**Европада куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек оешмасы (ОБСЕ) бинасында төрле ил вәкилләре катнашындагы чара кысаларында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Россиядә тыныч җыеннар һәм ассоциацияләр темасына багышланган утырышның модераторы булды. Аны Венада Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Кырым мөфтияте оештырды.**

Төрле ил дипломатлары, хокук саклау оешмалары һәм ММЧ вәкилләре катнашкан утырышта Россия төбәкләрендәге иҗтимагый оешмаларның, шул исәптән дини оешмаларның да эшчәнлеге каралды. Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан мөфтиятенең иҗтимагый эшләре, интернет челтәрдә дәгъвәт эшләрен оештыруга кагылышлы мәгълүматларны җиткерде. Татарстанда ислам үсеше һәм динара мөнәсәбәтләр хакында да әйтте.

Камил хәзрәт Сәмигуллин Австриянең башкаласы Венага Европада куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек оешмасының (ОБСЕ) демократик институтлар һәм кеше хокуклары буенча бюросы чакыруы буенча барган иде.

# Мөфтият вәкилләре эшмәкәрләр бизнес-форумында катнашты

**Казанның Марриотт кунакханәсендә Марокко һәм Татарстан эшмәкәрләре катнашында бизнес-форум үтте. Марокконың Тышкы сәүдә министры Мөхәммәд Аббу җитәкләгән делегациягә илнең 40ка якын эре компания вәкилләре керде.**



Форумның эшендә Татарстан мөфтие исеменнән ТР МДНнең аппарат җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, "Хәләл" стандарт Комитеты җитәкчесе Марат Низамов катнашты. Шулай ук мөселман эшкуарлары ассоциациясе, ТР Сәүдә-сәнәгать палатасы вәкилләре һәм күп санлы Татарстан эшмәкәрләре дә бар иде.

Марокко делегациясе форум барышында авыл хуҗалыгы, тукыма сәнәгате, электроэнергетика, металлургия, хәләл өлкәләрендә җитештерелгән продукция һәм эшчәнлекләре белән таныштырды.

Рәсми очрашу ахырында ТР МДНнең аппарат җитәкчесе Ришат Хәмидуллин Марокконың Тышкы сәүдә министры Мөхәммәд Аббуга Татарстан мөфтие исеменнән истәлекле бүләк тапшырды.

# ЯШЬ КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР КОРЪӘН ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ХАКЫНДА СӨЙЛӘШТЕ



**ТР Язучылар берлегенең һәм "Әллүки" иҗат берләшмәсенең яшь, талантлы, өметле, иҗат рухы белән янган шагыйрьләре, әдәбият сөючеләр Диния нәзарәтенә "Коръән һәм әдәбият" дип аталган очрашуга җыелды.**

Мәртәбәле кунаклар арасында язучы, җәмәгать эшлеклесе Рабит ага Батулла, нәзарәтнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, Язучылар берлеге рәисе урынбасары шагыйрь Рәмис Аймәт һәм "Әллүки" иҗат төркеменең кураторы язучы Халисә Ширмән бар иде.

Очрашуны Нияз хәзрәт Коръән аятьләре белән башлап җибәрде һәм бик тә тәфсилле итеп татар дини әдәбиятына күзәту ясады. Рабит Батулла бүгенге көн кадагында торган мәсьәләләргә тукталып, әдәбият белән диннең бәйләнешенә кагылышлы сорауларга дөрес җавап биргән яшьләргә үзенең китапларын да бүләк итте. Рәмис Аймәт бүгенге яшь татар язучылары һәм шагыйрьләренә булган игътибар, иҗат кешеләренә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сәләт турындагы фикерләре белән уртаклашты.

Әлбәттә, кичәнең иң күркәм өлеше - яшьләрнең иҗат җимешләре белән танышу булгандыр. Фәнил Гыйләҗев, Алсу Нургатина, Айдар Җамал, Дания Нәгыймуллиналар тирән эчтәлекле әсәрләрен укып күрсәттеләр. Яшьләр мондый очрашуларның дәвамлы булуын теләп, аралашып яшәргә, дигән ният белән таралыштылар. Кичәне Диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова алып барды.

***

Апрель аенда татар яшьләре тормышында тагын бер зур вакыйга көтелә.

"Мин татарча сөйләшәм!" акциясе үзенең 10 еллыгын билгеләп үтә. Аның быелгысы берничә чарадан тора: республика мәктәпләрендә бәйге уздыру, "Татар-дозор" квест-уены, "Татарча хатасыз" фотомарафоны, "Тяжело с татарским" антипремиясен тапшыру, Яр Чаллы, Түбән Кама, Алабуга шәһәрләре буенча концерт турлары һәм Бауман урамында гала-концерт.

"Мин татарча сөйләшәм!"не Татарстан Мәдәният министрлыгы ярдәмендә Бөтендөнья татар яшьләре форумы, Татарстанның Фән һәм мәгариф министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы оештыра. Беренче тапкыр әлеге чараны 2006 елда зыялы татар яшьләрен берләштергән "ҮZЕБЕZ" креатив хәрәкәте уздырган иде.

# ТАТАРСТАНГА ХАҖ СӘФӘРЕНӘ 1500 КЕШЕЛЕК КВОТА БИРЕЛДЕ



**Быел изге хаҗ сәфәренә Татарстаннан 1500 кеше бара ала. Бу хакта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәскәүдә Федерация Советында үткәрелгән 2015 елгы хаҗ сезонын оештыруга багышланган җыелыштан соң хәбәр итте.**

Быел Россия күләмендә хаҗга 16400 квота каралган. Узган ел да квота күләме шулай ук иде. 2015 елдан башлап хаҗга бары тик яңа тәрдәге - электрон чиплы чит ил паспорты белән генә барып була.

Хаҗиларның Согуд Гарәбстанына килүе 16 августтан башлана, туган илләренә алар 12 ноябрьдә әйләнеп кайтырлар дип көтелә.

***

Республика районнарында хаҗ турында семинарлар башланды. "ДУМРТ ХАДЖ" программасы хезмәткәрләре Әлмәт һәм Түбән Кама шәһәрләре үзәк мәчетләрендә халык белән очрашулар үткәрде инде. Программа җитәкчесе Ранис хәзрәт Вахитов һәм Диния нәзарәтенең халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге җитәкчесе Хәйдәр Камалетдинов "ДУМ РТ ХАДЖ" тәкъдим иткән яңа программалар белән таныштырды. Мондый семинарлар Казанда һәм республикабызның башка районнарында да оештырылыр дип көтелә.

**(Теманың дәвамы 16 нчы биттә)**

# АВЫРУ БАЛАЛАРГА ТЕРНӘКЛӘНҮ ӨЧЕН "ТЫНЫЧ БАКЧА" КИРӘК

**Казандагы Республика балалар клиника хастаханәсе территориясендә "Тыныч бакча" дип аталган рухи комплекс барлыкка киләчәк. Биредә мәчет, чиркәү, парк һәм спорт мәйданчыгы урнашачак. Шушындый үзенчәлекле бакча булдыру турындагы килешү Татарстан Сәламәтлек министрлыгы, Республика балалар клиника хастаханәсе, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Казан епархиясе тарафыннан әзерләнде һәм расланды.**

Килешүгә кул куйганчы "Тыныч бакча"ның электрон презентациясе уздырылды. Проект хакындагы сөйләшүдә ТР МДН Аппараты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, сәламәтлек саклау министры урынбасары Ринат Җәләлетдинов, хастаханәнең баш табибы Рафаэль Шәвәлиев, Анжела Вавилова исемендәге фонд җитәкчесе Владимир Вавилов, митрополит Анастасий атакай һәм башкалар катнашты.



Мәчет һәм чиркәү хастаханәгә килгән һәр кеше өчен ачык булачак. Авырулар да, аларның якыннары да дин әһелләренә үзләре теләгән вакытта мөрәҗәгать итә алачак. "Тыныч бакча"ны бу елның август ае ахырында ачарга җыеналар.

# СУСЛОНГЕРДА МӘРХҮМНӘР РУХЫНА ДОГА КЫЛДЫЛАР

**Татарстанның Арча һәм Әтнә районнарыннан дистәләгән кеше Суслонгерга барып, сугыш вакытында андагы лагерьда мәрхүм булганнар истәлегенә чардуган белән мемориаль такта куйдылар. Әлеге чарада район хакимияте вәкилләре, сугыш каһарманнары, дин әһелләре катнашты. Мари Иленең Звенигов районы Суслонгер бистәсендә куелган обелиск янәшәсенә чардуган белән гранит таш урнаштырылды, веноклар салынды. Аннары Арча районы имам-мөхтәсибе Раил хәзрәт Гыйләҗев мәрхүмнәр рухына багышлап дога кылды.**

Суслонгер лагере Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 елның июленнән 1943 елның ноябренә кадәр эшли. Бистәдән 10 чакрым ераклыкта - урман эчендә урнашкан бу лагерьның вазыйфасы - рус телле булмаган халыкларны - татарларны, башкортларны, чувашларны... рус теленә өйрәтү һәм курсантлардан пулеметчылар, артиллеристлар, танкка каршы ата торган мылтыклылар взводы командирлары әзерләү була. Бу өйрәнүләрне ун меңнәрчә солдат үтә. Бирелгән булганнарның хатирәләренә караганда, коточкыч җәфалар күреп, авырлыкларга чыдый алмыйча, бик күпләре мәрхүм булган.

Суслонгерга барып, вафат булганнарны искә алуны, алар рухына багышлап дога укуны һәм истәлек ташы урнаштыруны Арча районы хакимияте башлыгы Нуриев Илшат Габделфәрт улы оештырды. Чардуганны Фәрит Шаһиев эшләгән, "Металл" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җитәкчесе Лилия Гарәфиева металл белән булышкан, Арча егетләре граниттан таш ясап, истәлек язуы язганнар.



# МӘСКӘҮ УРАМНАРЫНА ТИЗДӘН КҮЧМӘ МӘЧЕТ ЧЫГА

**Россиядә беренче буларак мобиль мәчеткә акча җыю уңышлы төгәлләнде - барлыгы 851 мең сум күләмендә акча җыелган.**

Бу проектны тормышка ашыруда бөтен Россия мөселманнары катнашты. Дөрес, эш барышында проект кайбер үзгәрешләр дә кичергән - вагонны автобуска алыштырырга туры килгән. Автобусның өстенлекләре бәхәссез: күп урын алмаса да күбрәк кешене сыйдыра, туктарга да җайлы... Мәчет-автобус Казанда җиһазландырыла, ул аерым тәһарәтханә һәм намаз уку залыннан тора.



**Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһы Тәгалә исеме белән... Мактауларыбыз Аллаһы Тәгаләгә... Аның Илчесе Мөхәммәд Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын...**



# ҮЗ СҮЗЕНӘ ТУГРЫ БУЛУ КЕШЕНЕҢ ӨМЕТСЕЗ ХӘЛЕН ЯХШЫГА ҮЗГӘРТӘ АЛА

Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай ди: "Кешене ялганчы дип атар өчен, аның бөтен ишеткәнен сөйләве дә җитә". (Бу хәдисне Мөслим тапшыра.) Имам Нәвәви Мөслим сахихка шәрехендә болай дип яза: "Бу текстларда бөтен ишеткәнне дә сөйләүнең тыелган булуы турында әйтелә. Чөнки кеше булган нәрсәне дә, ялганны да ишетә, шуңа күрә бөтен ишеткәнен дә тапшыра башласа, ялган хәбәрне дә тапшыра".

Танылган мөселман Ибраһим бин Әдһәм болай дигән: "Кеше җанын ике нәрсә тарката: байлыгы һәм сөйләшүләре арту".

Акыллы мөселман бөтен ишеткәнен дә сөйләми. Дөрес гамәлләр кылу һәм дөреслекне сөйләү кешенең үзенә файда китерә. Бервакыт бер сахабә Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) янына килә дә болай ди:

- Ий, Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм)! Миңа ислам дине турында, бүтән сораулар бирмәслек итеп, сөйлә әле.

Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дип җавап кайтара:

- "Мин Аллаһы Тәгаләгә ышанам" дип әйт тә, шуннан соң дөреслекне генә сөйлә.

Бервакыт мөселманнар хәлифе Гомәр бин әл-Хаттаб (радыйаллаһу ганһү) сахабәләр арасында утырганда ике кеше бер егетне кулларыннан тотып алып килләр дә болай диләр:

- Ий, мөэминнәр җитәкчесе (радыйаллаһу ганһү), без кыйсас (үч алуны) таләп итәбез.

Гомәр әл-Фарук (радыйаллаһу ганһү) алардан сорый:

- Эш нәрсәдә? Ни сәбәпле үч алырга теләвегезне сөйләгәнче бернинди дә карар чыгара алмыйбыз. Бу егетне көчләп алып килүегезнең сәбәбе нинди?

Араларыннан берсе җавап бирә:

- Ий, мөэминнәр хәлифе (радыйаллаһу ганһү), бу егет бакчабызда безнең әтиебезне үтерде. Без аның да үтерелүен телибез. Үч алыйсыбыз килә.

Гомәр бин әл-Хаттаб (радыйаллаһу ганһү) егеткә мөрәҗәгать итә:

- Син бу турыда нәрсә дисең? Бу кешеләрнең сүзләре хакмы? Син чыннан да аларның әтиләрен үтердеңме?

Егет җавап бирә:

- Ий, мөэминнәр җитәкчесе (радыйаллаһу ганһү), бу кешеләр булган хәлне сөйлиләр. Миңа чынлыкта ничек булганны сөйләргә рөхсәт ит. Мин ерактан килдем. Юлда өч көн булу сәбәпле, ял итәсем килде. Атымны бу кешеләр бакчасы янында бәйләдем дә, ял итәргә яттым. Мин йоклаган вакытта, атым, ашыйсы килеп, бакчадагы хөрмә агачының ботагын сындырган. Атыма ташлар ыргыткан тавышка уянып киттем. Ташларның берсе атымның маңгаена туры килеп, ул үлде. Мин атымны бик ярата идем, моны күргәч, ачуым чыгып, ташны аны ыргыткан кешегә кире аттым. Таш аңа бәрелеп, ул да үлде. Минем аны үтерергә ниятем юк иде.

Моннан соң Гомәр бин әл-Хаттаб (радыйаллаһу ганһү) болай ди:

- Син үз сүзеңне әйттең, инде хәзер кыйсас мөмкин.

Егет болай ди:

- Туктагыз, туктагыз, мин сезнең карарыгызга буйсыначакмын, Коръән сүзе башка сүзләргә караганда көчлерәк. Ләкин җәзага тартылганчы минем ярдәмгә мохтаҗ бер ятим турында әйтәсем килә. Мин бу мәсьәләне хәл итәргә тиеш. Безнең әтиебездән мирас калды. Акчалар яшерелгән урынны мин генә беләм, ә кечкенә сеңелем белми. Бу акчаларны аңа тапшыру өчен миңа өч көн бирегез.

Гаепләүчеләрнең егетне тыңлыйсылары килми, ләкин Гомәр әл-Фарук (радыйаллаһу ганһү) болай диде:

- Син сүзеңдә тормаган очракта җаваплылыкны үз өстенә алучыны - гарантны тапсаң рөхсәт итәчәкмен.

Егет сахабәләргә күз сала, ләкин араларында таныш кешене таба алмый. Әбү Зар радыйаллаһу ганһүне күргәч, аның гарант була алуын әйтә.

Моны ишеткән сахабәләр гаҗәпкә калалар. Әбү Зар (радыйаллаһу ганһү):

- Мин аңа гарант булырга риза, - дип әйтә. - Эшләрен тәмамласын һәм өч көннән әйләнеп кайтсын.

Бу бөек сахабәнең кем икәнен бөтен кеше дә белгән. Шуңа күрә аның сүзләрен барысы да кабул итә. Егет китеп бара. Кешеләр өч көн узгач нәрсәләр булачагын көтә башлый. Вакыт уза. Сахабәләр хакимнәре янына җыелалар. Араларында Әбү Зар (радыйаллаһу ганһү) да була. Билгеләнгән вакыт якынлаша. Егет күренми. Моңа карамастан, Әбү Зар (радыйаллаһу ганһү) бер дә борчылмый. Гаепләүчеләр болай диләр:

- Ий, Әбү Зар (радыйаллаһу ганһү), без синең зур кеше булуың турында беләбез. Ләкин без әтиебез үлеме өчен җәза таләп итәбез. Син теге егетнең вакытында кире кайтуына гарант булырга ризалаштың. Ул кайтмаса, без җәза таләп итәчәкбез.

Гомәр хәзрәт (радыйаллаһу ганһү) хөкемне Коръән кушуы буенча тормышка ашырачагы турында әйтә. Әбү Зар (радыйаллаһу ганһү) Коръән кушуына буйсыначагын белдерә. Моны ишеткән сахабәләр борчыла башлыйлар. Кайберләре гаепләүчеләргә мөрәҗәгать итәләр:

- Әтиегез үлеме өчен сезгә йолым түли алабыз.

Ләкин әтиләрен югалткан гаепләүчеләр йолым алырга риза булмыйлар.

Билгеләнгән вакыт уза. Егет күренми, һәм Әбү Зар (радыйаллаһу ганһү), урыныннан торып, тәһарәт ала, җәзага әзерләнә. Моны күрүчеләрнең күзләренә яшь тула. Шул вакыт еракта тузан куптарып йөгереп килүче кеше күренә.

Ул йөгереп килә дә, болай ди:

- Көттергәнем өчен гафу итүегезне үтенәм. Туганнарыбыз еракка күчеп киткән булганнар. Мин аларны табып, сеңлемне һәм аңа тиешле акчаны аларга тапшырдым.

Бу сүзләрне ишетүчеләр гаҗәпләнүләреннән бер сүз дә әйтә алмыйлар. Йөзләрендә бер генә сорау: "Кем бу? Кайдан килгән?" Аларның гаҗәпләнүен күргән егет:

- Сез мине кире кайтмас, качар, дип уйладыгызмы? Ни сәбәпле гаҗәпкә калдыгыз? - дип сорый. - Мөселман - биргән

# КОРЪӘН ҮЛЕ ЙӨРӘКЛӘРНЕ ТЕРЕЛТӘ!

Мөхәммәд Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дигән: "Коръәни-Кәримне өйләрегездә еш укыгыз. Чөнки Коръән укылмаган өйләрдә бәрәкәт әз, кайгылар күп була, ә анда яшәүчеләр һәрвакыт тынычсыз булалар". Минем фикеремчә, без Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) сүзләренә колак салсак, йортларыбызда тынычлык булмауның сәбәпләрен тиз аңлар идек.

Йортында Коръәни-Кәрим нуры балкып тормаса, кеше җан тынычлыгына ирешә алмый. Бу бәрәкәттән мәхрүм булган кешенең җан тынычлыгына ирешүен күз алдына да китереп булмый. Йортта тынычлык булсын өчен иң башта Коръәни-Кәримдә кушылганнарны үтәргә һәм тыелганнардан тыелырга кирәк. Аллаһы Тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләре дә билгеле: "Коръән үле йөрәкләрне терелтә!"

Коръәни-Кәрим кешене депрессиядән һәм күңел тынычсызлыгыннан коткара. Ул өмет чыганагы булып тора. Коръәни-Кәримгә тотынучылар өметсезлеккә бирелмиләр. Чөнки өметсезлек кеше йөрәген үтерә, аны рухи яктан бетерә. Коръәни-Кәрим кешеләргә өметләр тулы тормыш бүләк итә, тормышыбыз турында уйланыр өчен борыңгы заман халыклары һәм цивилизацияләре турында сөйли. Безнең өчен иң мөһиме - Коръәни-Кәримгә ике куллап ябышу. Аллаһы Тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: "Коръәнне уку йөрәк дәвасы булып тора".

Күңел тынычсызлыгыннан бердәнбер дәва - Коръән. Коръән - теләсә нинди авырудан дәва. Коръәнгә гашыйк кешеләр авыруларыннан һәрвакыт дәва табалар һәм Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә ирешәләр. Мөселман кешесендә депрессия башланса, аңа тәһәрәт алып, Коръән укый башларга кирәк. Депрессиядән чыгуның бердәнбер юлы - Коръәни-Кәримне уку һәм тыңлау. Әлбәттә, дәва һәм рәхимлелек чыганагы булган Коръән генә кеше җанына тынычлык һәм яшәү теләге бирә ала. Без даими рәвештә Коръәни-Кәримне укырга тиеш!

Аллаһы Тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: "Коръәни-Кәримне укып һәм намаз кылып, кулларыгызны нур белән агартыгыз". Шулай ук Аллаһы Тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: "Коръәни-Кәрим - туры юлдан барырга булышучы якты нур. Аның аятьләре төгәл, искә алулар һәм нәсыйхәтләр белән тулы. Коръән - хакыйкать юлы". Түбәндә китерелгән аятьтә Аллаһы Тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм Коръәни-Кәрим әҗере турында болай ди: "Коръәнне укыгыз, чөнки Кыямәт Көнендә ул аны укучылар өчен яклаучы булыр". Кыямәт Көнендә яклаучысы булып Коръәни-Кәрим торгач, мөселманнар өчен бу бәхет түгелме?

Коръәни-Кәримне уку - Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү. Коръән - Аллаһы Тәгаләнең сүзләре булу сәбәпле, Коръән укучы кеше Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү әҗерен ала. Аллаһы Тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: "Кешенең Аллаһы Тәгалә белән сөйләшәсе килсә, Коръәни- Кәримне укысын". "Коръәни-Кәримне яттан өйрәнгән кешеләр - өммәтемнең иң хөрмәтле кешеләре". "Йөрәгендә Коръәни-Кәримнән бернәрсә дә булмаган кеше ишелгән йорт сыман".

Дөрестән дә, йөрәгендә

сүзендә торучы кеше.

Ул кулларын күтәреп, болай ди:

- Я, Аллаһ, бу кешеләр әйләнеп кайтуыма нигә гаҗәпләнә? Иманымның нуры минем йөземне агартмаганмыни?

Бу сүзләрне әйткәндә аның күзләреннән яшьләр ага. Мөселманнар хакиме (радыйаллаһу ганһү) Әбү Зардан (радыйаллаһу ганһү) сорый:

- Ий, Әбү Зәр. Син бу егетнең әтисен беләсеңме? Аның нәселен беләсеңме?

- Юк, мин аны да, аның нәселен дә белмим. Сез минем аңа ни сәбәпле гарант булырга риза булуымны белергә телисездер.

- Әйе, - дип җавап бирә хәлиф.

- Ий, Гомәр әл-Фарук (радыйаллаһу ганһү). Сез мине барыгыз да беләсез. Минем ни рәвешле Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Илчесенә ышануым да барыгызга да билгеле. Мөхәммәд Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) миңа хөрмәт күрсәтә иде. Димәк, мин аны уңайсыз хәлдә калдыра һәм башкаларга, шундый кешеләр ярдәм күрсәтми, дип сөйләргә мөмкинлек бирә алмый идем. Шуңа күрә мин бу егеткә булышырга риза булдым.

Моны ишеткән гаепләүчеләрнең исләре китә һәм алар болай диләр:

- Ий, мөселманнар хәлифе (радыйаллаһу ганһү), без Аллаһы Тәгалә хакына хәлифәсстан баш тартабыз. Без аны гафу итәбез. Бу егет ниятләп үтеручe кешеләрдән түгел.

Шулай итеп, без биргән сүздә торуның кеше хәлен өметсездән яхшыга үзгәртә алуының матур мисалын күрдек.

Ислам - гүзәл дин. Күпме яхшы кешеләр тәрбияләп үстергән дин!

Ий, Аллаһ, мин синнән җәннәт һәм аңа якынлаштырган сүз һәм гамәлләр турында үтенәм! Җәһәннәм утыннан һәм аңа якынлаштырган сүз һәм гамәлләрдән саклавыңны үтенәм! Һәм минем өчен хәерле булганны гына насыйп итүеңне сорыйм! Амин.

---

Коръәни-Кәримнең бер сүрәсе дә булмаган кеше нинди начар хәлдә кала бит! Үз динен яраткан кеше, ким дигәндә, намазда укыла торган сүрәләрне өйрәнергә тиеш.

Безнең татар халкы Коръәни-Кәримне һәрвакыт яраткан, дөньядагы беренче басма Коръәнне безнең халык бастырып чыгарган, ә дөньядагы иң зур басма Коръәни-Кәрим хәзерге вакытта Татарстанның Болгар шәһәрендә.

Әгәр дә кеше намазда укыла торган сүрәләрне генә булса да өйрәнсә, бу аның йөрәгендә Коръәни-Кәримнән сүрәләр бар икәнлеген аңлата.

И, рәхимлеләрнең рәхимлесе булган Аллаһ! Безне, фани дөнья рәхәтлекләренә мавыгып, Синең Изге Китабың - Коръәни-Кәрим турында онытучылар тәкъдиреннән саклавыңны үтенәм. Амин...

# Сорау – җавап

***- Без үзебезнең мәрхүм туганнарыбызга ни рәвешле ярдәм итә алабыз?***

- Хәнәфи мәзһәбе галимнәре: "Кылган гамәлеңнең савабын башка бер кешегә тапшыру хокукы бар", - дип аңлата. Бу намаз укуму, ураза тоту, садака бирү яки хаҗ кылу, салават әйтү, Аллаһны тәсбих итү яки шуларга охшаш башка бер гамәлме - анысы мөһим түгел. "Рәддел-мохтәр" китабының 666 нчы битендә (I том) болай диелгән: "Башка кеше өчен хаҗ кылу мәсьәләсендә хәнәфи мәзһәбе галимнәре кешеләргә андый хокук - кылган гамәлеңнең савабын башка бер кешегә тапшыру хокукы бирелгән, дип ачыктаначык әйткән. Аның намаз, ураза яки садака булуы турында "Әл-Һидая" китабында да әйтелгән". Әмма "Әл-Мохит"тән "Әт-Татархания" китабының "Зәкят" бүлегендә болай диелә: "Нәфел садака бирүче үз савабын бар мөэмин вә мөэминәләргә тапшыру турында ниятләсә яхшырак булыр, чөнки аның бу савабы барысына да барып ирешә һәм үз савабыннан берни дә кимetelми. Бу Әһле Сөннәт вәлҗәмәгать фикере, ләкин имам Мәлик һәм имам Шәфигый намаз һәм Коръән уку кебек бәдәни гыйбадәтләрне бу исемлеккә кертмәгән, ягъни алар, садака яки хаҗ гыйбадәтләреннән аермалы буларак, бәдәни гыйбадәтләрнең саваплары мәрхүмнәргә барып ирешми, дигән. Мөгътәзиләләр исә, гыйбадәтнең нинди төре булуга карамастан, савабы бармый дип санаган".

"Рәддел-мохтәр" китабының 27 нче битендә (II том) болай дип әйтелгән: "Әд-Дәра Кутни түбәндәге хәдисне тапшыра: "Бер ир кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: "Әти-әниләрем исән вакытта мин аларга карата миһербанлы булдым. Алар хәзер вафат инде, мин аларга берәр ничек ярдәм итә аламмы?" - дип сораган. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: "Үз намазың белән бергә алар өчен дә намаз укы, үз уразаң белән бергә алар өчен дә ураза тот, хактыр ки, бу - алар өчен дә бүләк булыр", - дип җавап биргән.

Галидән (радыйаллаһу ганһү) тапшырыла ки, ул болай дигән: "Мөселман зираты янынннан үтеп баручы ун тапкыр "Ихлас" сүрәсен укыса һәм аның савабын мәрхүмнәргә багышласа, ул мәрхүмнәр санынча савап алыр".

Әнәснең (радыйаллаһу ганһү): "Ий, Аллаһының Рәсүле, без мәрхүмнәр исеменнән садака бирәбез һәм алар исеменнән хаҗ кылабыз, аларга дога укыйбыз. Бу аларга барып ирешәчәкме?" - дип сораганы җиткерелә. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Әйе, бу аларга барып ирешәчәк. Алар моңа сезнең бирәрегез бүләк ителгән бер тәлинкә сый-нигъмәткә шатланган кебек шатлана" (хәдисне Әбү Хәфес әл-Әкбәри тапшырган).

Аллаһыга яхшырак билгеле.

***- Кош-кортлар, хайваннар җеннәрне күрәме?***

- Хәдисләргә таянып, без кайбер хайваннарның җеннәрне күрүе турында әйтә алабыз.

Әбү Һурайра (р.г.) тапшырганча, Аллаһ Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Әтәчләр кычкырганда, Аллаһтан күбрәк сорагыз, чөнки алар шул мизгелдә фәрештәне күрде. Ишәкнең кычкырганын ишетсәгез, шайтаннан Аллаһ ярдәменә омтылыгыз, чөнки ишәк ул вакытта шайтанны күрде" (Бохари, Бәдел-халк: 15, № 3127, 3/1202; Мөслим, Әз-Зикер вә дога: 20, № 7096, 8/85).

Кайбер галимнәрнең фикере буенча, әтәчләр кычкырганда үтенеч белән Аллаһка мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Бу шушы мизгелдә кылына торган гыйбадәтләргә фәрештәләр "Әмин" дип тору белән бәйле.

Дәүди әйткәнчә, әтәчләрдә үзебездә булдырырга кирәк булган кайбер берничә сыйфат бар: матур тавыш, иртә тору осталыгы, юмартлык, көнләшү һәм гаилә иминлеге.

Җәбир ибне Габдиллаһтән (р.г.) тапшырылганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Төнлә этләр улаганын яки ишәк кычкырганны ишетсәгез, шайтаннан Аллаһ ярдәменә ашыгыгыз, чөнки алар сез күрергә мөмкин булмаганны күрә".

***- Җеннәр нәрсәдән яралтылган?***

- Бу мәсьәлә Коръәни-Кәримдә дә, Рәсүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә дә яктыртылган.

Коръәни-Кәримдә болай диелгән: "Җеннәрне дә электән үк уттан яралттык" ("Хиҗр (Хиҗыр иле)" сүрәсе, 27 нче аять); "Җеннәрне Ул уттан барлыкка китерде" (Рахмән (Рәхимле)" сүрәсе, 15 нче аять).

Коръәни-Кәримдә җеннәр яралтылган утны сурәтләгәндә ике термин кулланыла: "сәмүм" һәм "мариҗ". Ибне Габбас (р.г.) сәмумның нәрсә икәнен аңлатып, болай ди: "Бу үтерә ала торган җил яисә төтенсез ут". Ибне Мәсүд (р.г.) исә болай ди: "Сәмүм - җәһәннәм утының җитмештән бер өлеше" ("Тәфсирүл-Куртуби", 10/23). Мариҗны Ибне Габбас түбәндәгечә аңлата: "Бу утның кызыл, яшел һәм сары төсләре кушыла торган урын". Имам Ләйс сүзләренә караганда, мариҗ исә утның иң якты һәм иң көчле өлеше булып тора ("Тәфсирүл-Куртуби", 17/161).

Шулай итеп, югарыда язылганнардан чыгып, җеннәрнең төтенсез көчле уттан яралтылганы ачыклана.

***- Ничек дога кылсаң дөрес була? Аллаһыга ялварганда кулны өскә күтәреп һәм аннан соң битне сыпырырга кирәкме? Моңа дәлилләр бармы?***

- "Әл-Фәтава Әл-һиндия" китабында әйтелгән: "Безгә килеп җиткән һәм укырга рөхсәт ителгән догаларны ничек итеп уку түбәндәге аятькә һәм "Әл-Мохит" китабына нигезләнә: "Аллаһының исемнәре - иң гүзәл исемнәр, шул исемнәр белән дога кылыгыз!.." ("Әгъраф (Пәрдә)" сүрәсе, 180 нче аять).

Дога кылганда учларны, зур булмаган аралык калырлык итеп булса да (йомылмас өчен), җәю яхшырак. Бер учны икенчесе өстенә куярга кирәкми. Моңа мөмкинлек булмаса, әйтик, каты суыклар вакытында, тырпайган имән бармаклар җәелгән уч ролен үти, ягъни имән бармактан кала башка бармаклар йодрыклана".

"Әл-Куния" китабында исә кулларны күкрәккә каршы күтәрүнең мөстәхәб (хупланылган) гамәл икәнлеге әйтелә.

Кайберәүләр дога кылганнан соң битне сыпыру мәҗбүри түгел дип әйтә, ләкин күпчелек галимнәр бу гамәлне кирәк дип саный. "Әл-Фәтава" Әл-һиндия" китабында моңа дәлил бар.

***- Мин тешемә пломба куйдырдым. Госел коенган вакытта су пломба астында калган теш өслегенә кадәр үтми. Мондый госел дөрес буламы?***

- Сезнең тәһарәт алуыгыз һәм госелегез дөрес, чөнки бу очракта пломба салу зарур. Пломба куйдырмаган очракта тешнең нервысына һәм ул кешенең сәламәтлегенә зыян килергә мөмкин. Госел коенганда пломба астындагы тешне юу кыен, ләкин шәригать бу кыенлыкларны юкка чыгара. Моңа Кәламе шәриф аятьләрендә түбәндәге дәлилләр китерелә: "Ислам динендә Аллаһы сезгә тарлык кылмады, бәлки киңлек кылды" ("Хаҗ" сүрәсе, 78 нче аять). "Аллаһы сезгә җиңеллек тели, авырлык теләми" ("әл-Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 185 нче аять). "Аллаһы сезгә тарлыкны теләми" ("Маидә" сүрәсе, 6 нчы аять).

Бу җәһәттән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Хактыр ки, ислам дине җиңел дин, тиешеннән артыклык белән сезнең арагыздан беркем дә аны авырайтмасын, андый вакытта ул аны җиңәр" (Сахих Бохари).

"Әл-әшбах ван нәзәир" китабында Бине Нөҗәим әйткән: "Зарурлык шартларында чикләүләр булырга мөмкин". Мәсәлән, госел коенганда хатынкызларга толымнарын тарату мәҗбүри түгел, гәрчә ул моны эшли алса да. Ә пломба астында калган тешне, ул пломбаны алып ташламый торып, гомумән юып булмый. Бу - чәчне таратуга караганда да авыррак.

"Ас-сиая" китабында Габделхәй әл-Ләкнәви әйткән: "Шул турыда фәтва бирелә: әгәр ашаганнан соң тешләр арасында ризык кисәкчекләре калса һәм җәнебтән соң госел коенганда тешләрнең өслекләре су белән тулысынча юылуына алар комачауласа - бу вакытта госел башкарылган булып исәпләнә (Ас-сиая. - Т.I - 125 б.). Шул ук китапта болай дип әйтелгән: "Кулларын кына белән буяган кешенең госеле дөрес башкарылган булып санала. Галимнәр моны хәрәҗ (кыенлыклар) аркасында мөмкин дип исәпләгән. Тәнгә май сөртеп госел коенганда да, гәрчә бу вакытта су тирегә кадәр үк үтеп кермәсә дә, мондый госел дөрес булып санала (Әс-миая. - Т.I - 258 б.; Рәддел-мохтәр. - Т.I. - 114 б.).

"Рәддел-мохтәр" китабының I томында, 114 нче биттә тагын болай диелгән: "Госел яки тәһарәт алуга чебен экскрементлары, кына, пычрак һәм җир комачауламый. Бу - "Әл-мунья" һәм "Әз-заһира" китапларында чыгарылган фәтва. Анда кына, балчык турында ачык әйтелгән һәм галимнәр моның зарурлык булу аркасында мөмкин икәнен аңлаткан.

Безнең очракта да бу зарурлык булып санала.

Ә Аллаһыга яхшырак билгеле.

***- Намаз укып бетергәннән соң киемемдә кан табы күрдем. Бу тапның кайчан барлыкка килгәнлеген белмәгәнлектән, миңа ул намазны һәм аннан алда укылган намазларымны кабаттан укырга кирәк булачакмы?***

- "Әл-Фәтава әл-һиндия" китабында язылганнардан чыгып, сезгә бер намазыгызны да кабаттан укырга кирәк булмаячак. Әлеге хезмәтнең I томында (61 нче бит) болай диелгән: "Кем дә булса үзенең киемендә (яки тәнендә) бер дирһәмнән зуррак (бу - намаз укырга мөмкинлек бирмәгән күләмдәге нәҗес була) зур нәҗес (кан, сидек һ.б.) табып алса, һәм ул аның үз киеменә кайчан эләккәнен белмәсә - галимнәрнең бердәм һәм ышанычлы фикере буенча - ул үз намазларыннан берсен дә кабаттан укымас.

Бу хакта имам Сәрахсиның "Мүхит" һәм "Әл җәһра әннәйра" китапларында да әйтелә.

Аллаһыга яхшырак билгеле.

Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

# Рәҗәп аеның фазыйләтләре

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: "Рәҗәп – Аллаһының ае, шәгъбан – минем аем, ә рамазан – өммәтемнең ае". Бер кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: "Йә, Расүлуллаһ, ни өчен рәҗәп Аллаһның ае соң ул?" – дип сорагач, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип аңлаткан: "Бу айда чын күңелдән тәүбә итүчеләргә Аллаһы Тәгаләнең мәгъфирәте (ярлыкавы) иңә, бу айда кан түгү, сугышлар тыелган, бу айда Аллаһы Тәгалә бөтен пәйгамбәрләрнең догаларын кабул кылган һәм күп кенә әүлияләрне (изгеләрне) дошманнары кулыннан коткарган".**

Рәҗәп аеның беренче җомгасына каршы кичә "Рәгаиб кичәсе" дип йөртелә. Бу вакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе Габдулла белән әнисе Әминәнең никахлашкан кичәсе санала. Рәгаиб кичәсендә Аллаһ ризалыгы өчен Коръән укып, догалар-гыйбадәтләр кылынса, савапка ирештерер, иншә Аллаһ.

Рәҗәп аеның 26 нчы көненнән 27 сенә каршы төндә Мигъраҗ кичәсе була. Бу төнне Рәсүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһының кодрәте белән гадәти булмаган сәфәр кыла: борак (яшен тизлегендә оча торган) дип аталган хайванга атланып, Мәккәи-Мөкәррәмәдәге Хәрам мәчетеннән Кодүстәге (Иерусалимдагы) әл-Әкъса мәчетенә күчә. Шунда башка пәйгамбәрләргә имам булып алгы сафта намаз укый. Пәйгамбәребез алдына өч савыт куялар: берсендә – су, икенчесендә – сөт, өченчесендә шәраб була. Ул сөт салынган савытны сайлый. Моны күргән Җәбраил фәрештә: "Әй, Мөхәммәд, син һәм синең өммәтең дөрес юлда. Исерткеч эчү – хәрам!" – ди. Аннары Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Җәбраил фәрештә белән күккә менә. Анда җәннәт белән җәһәннәмне күрә, Аллаһ Раббыбыз белән сөйләшү бәхетенә ирешә. Аллаһы хозурына баргач ул: "Әттәхиййәту лилләәһи үәс-салә̄үәәту үәт-таййибәт", - дип сәламли, ягъни: "Тел һәм тән гыйбадәтләребезнең барысы да фәкать Аллаһы өчен генә". Аллаһы Тәгалә: "Әс-сәләәму гәләйкә әййүһән-нәбиййү үә рахмәтуллааһи үә бәракәәтүһ", - дип җавап бирә, ягъни: "Әй, Пәйгамбәр, сиңа Раббыңның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын". Моңа каршы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: "Әс-сәләәму гәләйнә үә гәләә гибәәдил-лләәһис-салихиин", - ди, ягъни: "Сәлам безгә һәм Аллаһы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә булсын". Шуннан соң фәрештәләр: "Әшһәдү әл-ләәә иләәһә илләл-лааһү үә әшһәдү әннә Мухәммәдән гәбдүһү үә расүлүһ", - дип шәһадәт кәлимәсен әйтә, ягъни: "Чын күңелдән шаһитлык бирәбез ки, бер Аллаһыдан башка һичбер илаһ юк, Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм – аның колы һәм Илчесе". Бу сүзләрне без барыбыз да намазда "Әттәхият"кә утыргач әйтәбез, ягъни өч затның – Аллаһы Тәгаләнең, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәм фәрештәләрнең әйткән сүзләрен кабатлыйбыз. Шуңа күрә хәдис-шәрифтә: "Намаз – мөэминнең мигъраҗы", - дип әйтелгән. Димәк, без намазда Аллаһы Тәгалә белән сөйләшәбез, аңа мөрәҗәгать итәбез, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аңа якын булабыз. Шундый олуг бәхеткә көн саен биш тапкыр ирешәбез.

Аллаһы Тәгалә шушы кичәдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 3 бүләк тапшыра:

- биш вакыт намаз фарыз кылына;

- "Сыер" сүрәсенең ахыргы аятьләре бирелә;

- Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Кыямәт көнендә өммәтен яклау хокукы бирелә.

***"Шура" журналыннан кыскартып алынды***



# ХӘЗРӘТКӘ СОРАВЫМ БАР

*Әссәләәму галәйкүм, хөрмәтле редакция хезмәткәрләре. Минем хәзрәтләргә берничә соравым бар, шуларга газетада җаваплар урнаштырсагыз иде. Ихтирам белән Тукай районы Яңа Бүләк авылыннан* Мөдәрис ХАҖИЕВ.

**Сорауларыгызга ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе, Апанай мәчете имамхатыйбы** Нияз хәзрәт САБИРОВ **җавап бирә:**

- Гозерле кеше укылачак намаз вакыты кергәнче тәһарәт алса, аның тәһарәте дөрес буламы?

- **Авыру сәбәпле бер намаз дәвамында тәһарәтле була алмаган кеше – (мәсәлән, борыныннан даими кан чыгып тору, күзләреннән һәрчак лайлалы яшь агу) сахибе гозер (гозерле) дип атала. Андый кешегә һәр намаз өчен аерым тәһарәт алу тиешле. Шул гыйбадәте вакытында авыру сәбәпле тәһарәте бозылса да, намазы дөрес булып санала.**



**Гыйбадәт вакытында нәҗесләре агып торса да, тәһарәте дә, намазы да бозылмаган санала, әмма бер намаз өчен алынган тәһарәт, икенче намаз өчен бозылган санала. Авыру сәбәпле аккан нәҗес, икенче намаз вакыты кергәнче тәненә я киеменә тисә дә, шул вакыт эчендә нәҗес булып саналмый. Икенче намазның вакыты кергәч, ул нәҗес булып санала, гыйбадәтне үтәү өчен ул киемне юарга яки алмаштырырга кирәк. Шуңа күрә гозерле кеше укылачак намаз вакыты кергәнче тәһарәт алса, ул тәһарәт намаз вакыты кергәнче дөрес булыр. Намазның вакыты кергәч, аңа янә тәһарәт алу тиешле.**

- Зират эчендә кыйбла якта җеназа намазы уку дөрес буламы?

- **Каршыда каберләр булмаса, зират эчендә җеназа намазын укырга мөмкин. Каршыда кабер булган очракта, кабер белән имам арасында сутра (киртә) булырга тиешле. Ул киртәнең озынлыгы ким дигәндә ярты метр, киңлеге бер бармак кадәр булырга тиеш.**

# ШӘҺАДӘТ

**Ислам өндәүләренә иярергә теләгән аңлы балигъ булган кеше эшләргә тиешле беренче нәрсә – ул шәһадәт сүзләрен әйтү. Шәһадәт сүзләрен әйткән кеше мөселман була. Шәһадәт таныклыгы түбәндәге сүзләрдән гыйбарәт:**

"Әшһәдү әллә иләәһә иллаллааһү үә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә расүлүһ". (Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат юклыгына, Мөхәммәднең Аллаһының колы һәм илчесе булуына шаһитлык кылам).

Кыска булуына карамастан, шәһадәт сүзләре бик тирән мәгънәле һәм үз эченә диннең барлык төп кагыйдәләрен дә сыйдырган. Шәһадәт – Исламның капкалары ул, кешене Ислам өммәтенең әгъзасы итүче сүзләр. Шәһадәт сүзләрен чын күңелдән, мәгънәсенә төшенеп, калебең белән ихлас ышанып әйтергә кирәк. Шәһадәт асылының төп шарты үзеңнең Исламга каршы килүче элеккеге карашларыңнан ваз кичү һәм динне гамәлдә тотудан гыйбарәт. Шәһадәтне гарәп телендә мөселманнар барында әйтергә кирәк.

Исламны яңа кабул итүче кеше, гадәттә, диннең барлык нечкәлекләрен һәм шәригать таләпләрен белеп бетермәс. Башлангычта аңа гомуми дин белемнәре һәм исламның хакыйкый дин булуына ышануы да җитә. Әгәр дә кешегә нинди дә булса сорау аңлашылмый икән, "Мин моңа пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә ссәлләм җиткергән рәвештә ышанам", дигән фикерне баштан чыгармаска һәм белемле кешеләрдән аңлатмасын сорашырга кирәк.

***"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән***

# ТӘҺАРӘТ ДОГАЛАРЫ

### Тәһарәт ала башлаганчы укыла торган дога

"Әлхәмдү лилләәһилләзиии җәгалә-ль мәәә-ә таһүүрау үә җәгалә-ль исләәмә нүүра" **(суны пакьләндергән һәм исламны нурландырган Аллаһка мактау булсын).**

### Авызга су алганда әйтелә

"Аллаһүммә әскыйни миң хәүдый нәбиййикә кәәсән ләәә әзъмә-ү бәгъдәһү әбәдән" **(Йә, Аллаһым! Миңа Пәйгамбәребезнең хәвызыннан (сулыгыннан) бер касә су бирсәң, аннан соң мәңге сусамас идем).**

### Борынга су алганда укыла

"Аллаһүммә ләә тәхрумни раихәтә нәгиимикә үә җинәәник" **(Йә, Аллаһым! Мине нигъмәтләреңнән һәм җәннәтеңнең хуш исләреннән мәхрүм калдырма).**

### Битне юганда укыла

"Аллаһүммә бәййидъ үәҗһи бинүүрикә йәүмә тәбъйәдду вүҗүүһун үә тәсүәдду вүҗүүһ" **(Йә, Аллаһым! Бер төркем йөзләрнең агарып, икенче бер төркем йөзләрнең каралып калачак көнне минем йөземне дә агарт).**

### Уң кулны юганда укыла

"Аллаһүммә әгътыйни китәәби бийәмиини үә хәәсибни хисәәбән йәсиира" **(Йә, Аллаһым! Китабымны уң яктан бир һәм хисабымны җиңеләйт").**

### Сул кулны юганда укыла

"Аллаһүммә ләә түгътыйни китәәби бишимәәли үә ләә мин үәрааи заһри үә ләә тухәәсибни хисәәбән шәдиидә" **(Йә, Аллаһым! Миңа китабымны сул ягымнан һәм артымнан бирмә, миңа кырыс хисап насыйп итмә).**

### Башка мәсех кылганда укыла

"Аллаһүммә әзыйлләни тәхтә зыйлли гәршикә йәүмә ләә зыйллә илләә зыйллүк" **(Йә, Аллаһым! Гареш күләгәсеннән башка берниндә күләгә булмаган көнне миңа Гаршеңнең күләгәсендә басып торырга насыйп ит).**

### Колакларны мәсехләгәндә укыла

"Аллаһүммә җгални минәл ләзиинә йәстәмигүүнә-ль каулә фәйәттәбигүүнә әхсәнәһ" **(Йә, Аллаһым! Мине бары тик хак сүзләрне генә тыңлаган һәм иң күркәм нәрсәләр турында гына ишеткәннәрдән кыл).**

### Муенны мәсехләгәндә укыла

"Аллаһүммә әгътикъ ракабәти минә-н нәәри үәхфәзъни минә-с сәләәсили үәль агъләәл" **(Йә, Аллаһым! Муенымны утыңнан азат ит, чылбырлардан һәм муенчак тимерләреннән сакла).**

### Аякларны юганда укыла

"Аллаһүммә сәббит кадәмәййә галә-с сыйраатый йәүмә тәзиллү фииһи-ль әкъдәәм" **(Йә, Аллаһым! Аяклар тая торган көндә минем аякларыма нык булырга насыйп ит).**

# Рухы гали, дингә ихтирамы бөек, милләткә мәхәббәте олуг Тукай

**Апрель – Тукай ае. Тукай шушы айны дөньяга килгән, үзеннән соң олы мирас калдырып, шушы айда бакыйлыкка күчкән. Җитмеш ел дәвамында аның дини шигырьләрен, исламга мөнәсәбәтен яшерергә маташсалар да, бүген хакыйкать һәркемгә ачык: динебезгә ихтирамы бөек булган Тукайның! Моннан бер гасыр элек нәшер ителгән газетадагы шушы мәкалә игътибарымны җәлеп итте. Ул "Дин вә мәгыйшәт"не укучыларга да кызыклы булыр дип уйлыйм.**

## "Нур" газетасында Тукай үлеме турында

Казан голәмә мөгътәбәрләреннән булган мулла Кәшшаф хәзрәт Тәрҗеманинең "Идел"дәге мәкаләсен гайнән(үзен) куябыз. Кәшшаф хәзрәтнең язуы Казан голәмәсенең Тукаев хакында булган садәсе (кайтаваз) дип беләбез.

***Кәшшаф Тәрҗеманов яза:***

Без Казан мөселманнары бүген хакыйкый шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаев җәнабләрен дәфен итеп илә йәүмил-Кыямәһ (Кыямәт көненә кадәр) аннан аерылдык.

Мәрхүм бик яшь вакытында вафат итеп заиг (югалган) булуына тәәссеф (үкенеч) вә тәәссеремне (тәэсирләнү) изһар (ачык) итәмен. Габдулла әфәнде гаять истигдәдле вә табигый шагыйрь икәне аның шигырьләрен укыган һәркемгә мәгълүм булганга, ул тугрыда мин тәфсил итмәймен.

Аның башкаларга нисбәтән күп җиһәтләрдән артыклыгы өстенә иң зиядә әһәмиятле вә шайан тәкъдир җиһәте рухы гали, дингә ихтирамы бөек, милләткә мәхәббәте олугъ булуы иде.

Берничә еллар элек мәмләкәтебездә булган гомуми агымга ияреп күбрәк яшьләремездә дингә тагън (бәрү) итү яки милләткә әһәмият бирмәү кеби зарарлы гадәтләр мода хөкемен алган иде. Байтак мөхәррирләр вә шагыйрьләр бу "авыру" илә мөбтәлә иде. Ләкин табигате гали (бөек), дини хисе куәтле булган Габдулла әфәнде андый ваклыкларга тәнәззел итмәде (төшмәде). Үзенең үткен каләмен, хисле шигырьләрне һич бервакыт андый зарарлы нәрсәләр илә былчыратмады. Бәлки динне тәгзыйм (зурлау) вә дингә ихтирам илә калебләрне мөсәххәр итәрлек ихсәсле, тәэсирле шигырьләр язды".



Габдулла ТУКАЙ

### Таян Аллага

Әй бәһале, әй кадерле,
әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның,
һәрдәм таян син Аллага!

Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу
җиһанда якты юл;
Ул - рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә
күп шәфкатьле ул!

Саф әле күңлең синең, һичбер
бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр
әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең - бар
лык вөҗүдең пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың,
йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә
кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры
юл бар гаршенә!

Әй бәһале, әй кадерле,
әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның,
һәрдәм таян син Аллага!

_____

Гаршенә - югарыга, күккә.

### Тәәссер

Гомернең иң читен, җайсыз,
уңгайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә
кайгының мин утында,

Укыйм тиз-тиз күңелдән бер
гаҗаиб сүрә Коръәннән, -
Газаплар мәгънәви бер кул
илән алынадыр җаннан.

Оча дилдән бөтен
шик-шөбһәләр,
һәм мин җылый башлыйм:
Яңакларны мөкаддәс күз
яшемлә энҗели башлыйм.

Бөтенләй сафлана күңлем;
укыйм иман, булам мөэмин;
Килә рәхәт җиңеллекләр:
хәлас булам авыр йөкдин.

Ходайа! Син тыйган эшләр
тәмам әкътагъ вә әбтәр, дим;
Иям баш сәҗдәгә: "Аллаһехак!
Аллаһеәкбәр!" - дим.
***1908***

_______________

Тәәссер - тәэсирләнү.
Дил - күңел.
Хәлас булу - азат булу.
Әкътагъ вә әбтәр - кирәксез һәм яраксыз.

# Хәзерге байларга үрнәк булсын, дидек

*Татарстанда 2015 ел Диния нәзарәте тарафыннан "Татар дин галимнәре елы" дип игълан ителде. Ләкин галимнәребезне искә алганда тырыш сәүдәгәрләр, һиммәтле байлар, юмарт иганәчеләр турында да онытмаска кирәк.*

*Алар галимнәребезне: имам-мөәзиннәрне, остаз-мөгаллимнәрне тәэмин итеп торганнар, галимнәр укыткан шәкертләрнең, мәктәп-мәдрәсәләрнең чыгымнарын каплаганнар, белем ияләре язган китап-журналларны үз акчаларына бастырганнар. Мәсәлән, бер иске китапта штамп тора, анда "Садыйк Галикәев тарафыннан мөһер басылган китап һәр укучы балага акчасыз биреләдер" дип язылган, шулай итеп, балаларга бушлай китап таратканнар! Сезнең игътибарга шундый сәүдәгәрләребезнең берсе Мортаза Мусин турында бер язма тәкъдим итәбез. Хәзерге байларыбызга да үрнәк булсын әле.*

## Бәхетле рәвештә үлү

Быел май 18 ндә Яхшыбай карьясенең Минзәлә өязе хаҗи Мортаза бин Фәтхуллаһ әл-Мөхсини (Мусин) җәнабләре 4 айлык хасталыктан (ашказаны илә авырган) соң дөньядан китте. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун.

Бу әфәнде 64 яше тулган көнендә вафат буларак үзенә 35 яшьлек васыйятче Гыйрфәнеддин исемле углын калдырды. Зәүҗәсе, Габбас исемендә бер кечкенә угълы да калды.

Бу әфәнденең җәмигъ дәүләте (күчмә һәм күчемсез маллары) якынча 300 мең сумдыр. Бина, җир вә ашлык кеби малдан гыйбарәттер. Мортаза хаҗи үзенең сәламәтлегендә фарыз садакаларын - зәкят вә гошерләрен тиешенчә үтәүдән тыш нәфел садакадан да мәчет вә мәдрәсәләр төзеп аларны мөкәммәл тәрбия итә иде. Үзенең яшәгән авылы Яхшыбайга 15000 сумга төшереп таштан (кызыл кирпеч) 2 катлы бер мәчет бина итеп, үткән ел көзлектә генә тәмам итте. Бу мәчетнең асты 34 аршин, дүрт бүлмәле мәдрәсәдер. Моннан башка бер таш, бер агач мәдрәсәсе дә бар.

Үзенең туган авылы Бордыбаш карьясендә ике вә Анак дигән Яхшыбай күршесендәге карьядә бер мәчет вә шул санда олуг мәдрәсәләр бар.

Моның өстенә әтрафтагы карьяләрнең күбесендә мәчетләренә 100-200 вә 300 сум кеби иганә катыштырган урынлары сансыз күптер. Ушандак соңгы елларда бина ителгән мәдрәсәләргә иганә була иде. Әлеге өч авылның мәчет вә мәдрәсәләрен тиешенчә тәрбия итә иде.

Бу ихсанлы бай ул мәчет вә мәдрәсәләрне үзе үлү белән дә мәхрүм итмәде, бәлки аларга үзенең калган мөлкәтеннән якынча 90 мең сум микъдарын васыять итеп тиешенчә исбат белән яздырып калдырды. Шәригать буенча мәҗбүри булмаса да васыятьнамәсенә варисларыннан да имза иттерде. 90 меңнең дүрттән өч өлеше Яхшыбай мәчетенә, мәдрәсәләренә, мөдәррис вә мөгаллимнәренә сарыф ителергә билгеләнмеш. Ләкин шул ук малдан түгел, ә шуннан килгән керемнән тотылачактыр. Калган дүрттән бер өлеше шул рәвештә Бордыбашка билгеләнде. Яхшыбай мәдрәсәсендәге имам-хатыйб вә мөдәррис булган мәдрәсә мөдиренә һәр елда 200 сум эш хакы биреләчәктер.

Бар варислары - бер хатын, 3 угыл вә 2 кыздыр.

Аллаһ Тәгалә милләт байларыбыздан һәрберсенә дә шундый шәргый үлүләрне насыйп әйләсә икән. Бу әфәндене Әхмәд бай Хөсәенов соңында беренче санамак тиештер.

***Имам Шәйхелислам Хәмиди "Йолдыз", 1909, №410, 11 июнь.***

## Вакыф ни хәлдә?

1909 нчы сәнәдә Минзәлә өязе Яхшыбай карьясенең һиммәтле байларымыздан Мортаза әфәнде Мусинның милләт өчен 90 000 сум вакыф калдырып вафат булганлыгы вакытында газеталарда язылган иде.

Мәрхүм Шәйхелислам Хәмиди (1911 сәнәдә вафат) хәзрәттән (Мортаза әфәнденең мөдәррисе) бер вакытта "Бу кадәре зур сумманы нинди урыннарга, кайсы мәктәпләргә вакыф итте?" дип сораганымда: "Үзе ничә еллардан бирле торып, шушында вафат булган Яхшыбай мәдрәсәсенең бинасын төзәтеп һәм яхшы мөгаллимнәр китереп уку, укытуны ислах итәргә, үзенең асыл ватаны булган Борды башы мәдрәсәсенә утын, керосинны җиткерергә, тагы шушы ике авылның мәчетләренә утын, керосин һәм башка кирәк яракларын җиткерергә, әгәр керем болардан да артса, Яхшыбайның мөдәррисе (кем булса да), үзе мәгъкул күргән башка авыл мәдрәсәләренә бирергә хаклы булыр, дип әйтте" диде. Тагы хәзрәт вакыф вакытында булган хәлләрне сөйләргә керешеп, шул малны вакыф иткәч варислары арасында разый түгеллек гәләмәтен сизеп, Мортаза әфәнде варисларын катына җыйды да: "Мин малны җыйдым, бар малым да хәләлме, харамны, белмим. Менә мин шул Аллаһның ярдәме, үземнең иҗтиһадым сәясендә җыйган малымның өчтән берен (туксан мең сум) милләт юлына бирәм. Сезгә калганы да җитәр, тырышыңыз! Минем башта һич нәрсәм юк иде", диде. Моннан соң бер аз гайрәткә килеп, башындагы кәләпүшен салып: "Менә! Бу кәләпүшемнең дә өчтән бере милләт юлына булыр, мин бер тиенен калдырсаңыз да, сездән разый булачак түгелмен", дип әйтте", диде.

Менә бу хәлгә 7 сәнәләр үтеп китте инде, ләкин бу авылның мәдрәсәләрендә һичбер ислах күренми, бәлки Мортаза әфәнденең үзе сәламәт вакыттагыдан да түбән күренә. Мин милләтнең бер әгъзасы булганымнан һәм бу мал һичбер кешенең милкендә булмаенча, халис милләт малы булдыгыннан, вакыфка мөтәвәллиләреннән бу вакыф тугрысында сорарга үземне хаклы дип беләм һәм сорыйм: "Вакыф ни хәлдә? Елына күпме кереме була? Күпме чыгымы була? Нинди урыннарга тотыла? Мәдрәсәләргә нинди мөгаллимнәр китердегез? Күпмешәр вазыйфа алалар?" Миңа "Кояш" газетасы аркылы тәфсилле җавап бирсәңез иде.

***Зәки Уразайи әл-Мортышбашый 1915, №743.***

*Сәхифәне Фатих ХӘБИБ әзерләде*

# ШӘЛЕ БАЛАЛАРЫ ШӘМАИЛ ИҖАТ ИТӘ

**Казанга терәлеп үк торган Питрәч районы Шәле авылы мөселманнары матур, соклангыч гамәлләр кылып яши бүген. Балаларга дини белем һәм тәрбия бирүгә игътибар аеруча зур. Алар өчен төрле бәйрәмнәр, бәйгеләр үткәрелә, лагерьлар оештырыла бирелә. Мәчет, мәдрәсә җитәкчелегенә бу эштә мәхәллә халкы, җирле эшмәкәрләр дә бик теләп ярдәм күрсәтә.**



Быелгы язгы каникул көннәрендә дә "Гайнетдин" мәдрәсәсе каршында балалар өчен мөселман лагере оештырылды. 7 яшьтән 13 яшькә кадәрге 18 бала язгы каникул вакытында әлеге лагерьга теләп йөрде. Аларга гыйлемле остазлар ислам нигезләре буенча белем бирде, "Аллаһ – бар нәрсәне бар итүче", "Доганың файдасы, дога төрләре", "Иманның биш баганасы, пәйгамбәрләргә ышану", "Ата-аналарга карата әдәп кагыйдәләре" темаларына лекцияләр үткәрелде. Лагерь кысаларында волейбол, баскетбол ярышлары уздырылды, Казанның тарихи мәчетләренә экскурсия оештырылды.

Балалар Шәле авылының иң өлкән яшьтәге мулласы Габделхак хәзрәтнең хәлен белергә бардылар. Ул 50 елдан артык җирле мәчеттә имам булып торган һәм балаларның барысына исем кушкан мулла. Габделхак хәзрәт авылда үзенең гадәти булмаган шәмаилләре белән дан тота. Совет чорында да ул, буяулар табып, төрле шәмаилләр ясаган. Балалар аның эшләрен сокланып карады.

Бу очрашуның тагын бер хикмәте бар – "Гайнетдин" мәдрәсәсенә йөрүче балалар үзләре дә шәмаилләр иҗат итә. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте оештырган "Минем гаиләм шәмаиле" республика акциясендә катнашып, алар үз көчләрен сынап карарга булдылар. Мәдрәсә укучылары кулы белән иҗат ителгән шәмаилләрнең иң үзенчәлекләре сайлап алынып, Казанга республика конкурсына җибәрелде.

Ә 13 апрель көнне "Гайнетдин" мәдрәсәсендә балалар эшләреннән "Авылым шәмаиле" күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәгә куелган эшләр арасыннан бәләкәй осталар кулы белән агач тактага төшерелгән, тукымага чигеп ясалган шәмаилләр игътибарны аеруча җәлеп итә. Никадәр зур тырышлык куеп, күз нурларын түгеп, йөрәк җылысын салып башкарылган ул хезмәтләр! Бәлки шушы балалар арасыннан киләчәктә татар халкының борынгы мирасын торызучылар, шәмаил сәнгатенең чын осталары үсеп чыгар.

***Тимур ЛАТЫЙПОВ,***
***Питрәч районы***
***Шәле авылының***
***"Заһир" мәчете***
***имам-хатыйбы***











# Халкыбызның киләчәге ышанычлы

**"Ярдәм" мәчетендә "Сөембикә эниләре һәм сеңелләре" дип исемләнгән XVIII Бөтенроссия Коръән уку бәйгесе узды. Бәйгенең төп оештыручылары - "Мөслимә" хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы һәм "Ярдәм" хәйрия фонды.**







Әлеге бәйгедә Татарстанның төрле районнарыннан, Самара, Ульяновск, Мордовия, Удмуртия, Саратов, Чувашия, Мари Иленнән килгән 4 яшьтән алып18 яшькәчә 500 гә якын бала Коръән гыйлемен һәм ислам нигезләрен белүдә үз көчен сынап карады. Балалар шулай ук ислам тарихы һәм халкыбызның күренекле шәхесләре турындагы сорауларга да җавап бирделәр.

Бәйгене ачу тантанасында Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, Казан шәһәр хакимиятенең телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлеге хезмәткәре Илгиз Сарманов, Россия ислам институтының коръәнхафизлар әзерләү үзәге җитәкчесе урынбасары, жюри рәисе Габделәхәт Хәлилов, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, "Ярдәм" фонды вице-президенты Мәликә ханым Гыйльметдинова, "Мөслимә" хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Әлмира Әдиатуллина, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, журналистлар катнашты.

Килгән кунакларны һәм бәйгедә катнашучыларны Татарстан мөфтие исеменнән Рөстәм хәзрәт Батров сәламләде. Хәзрәтнең әйтүенчә, мондый конкурслар традицион исламны һәм татар мирасын популярлаштыру максатыннан уздырыла.

- Мин исламның һәм халкыбыз киләчәгенең ышанычлы кулларда икәненә ышанам. Сөембикә эниләре һәм сеңелләре Ш.Мәрҗани, Х.Әмирхан, К.Насыйри, А.Сафиуллин кебек дин белгечләренең дәвамчылары булсын өчен без барлык көчебезне куярга тиешбез, - диде Әлмира Әдиятуллина. Шулай ук ул балаларга белем биргән барлык мөгаллимнәргә, делегация җитәкчеләренә, мөфти һәм имамнарга, бәйгенең жюри әгъзаларына рәхмәтләрен җиткерде.

"Сөембикә эниләре һәм сеңелләре" бәйгесенең төп җиңүчеләре булып Мордовиядән Әхмәт Бәдретдинов һәм Мөхәммәд Әбдрәшитов һәм Татарстаннан Мөхәммәд Шакиров танылды.Тагын 35 бала Кол Гали, Кол Шәриф, Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхретдин исемендәге һ.б. номинацияләрдә җиңү яулады. Җиңүчеләрне халкыбызның танылган шәхесләре - Рәшидә абыстай Исхакый, Рабит Батулла, Харис хәзрәт Салихҗан, Хатип Миңнегулов, Абдулла хәзрәт Әдһәмов, Нияз хәзрәт Сабиров, Илдус Загидуллин, Айдар Хабетдинов, Резеда Сафиуллина, Луара Шакирҗан, Фәйрүзә Мөслимова, Рәшит Минһаҗ, Тәбриз Яруллин, Гөлназ Бәдретдинова һәм башкалар котлады. Алар "Сөембикә эниләре һәм сеңелләре" конкурсын югары бәяләп, балаларны олуг шәхесләребезгә лаек булырга чакырдылар.

Бәйгене күренекле мөселман тамадасы Гамил Нур алып барды. Чараны оештыруда шулай ук Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды, "Татэнергосбыт", "Ямашнефть", "Контр", "Горводзеленхоз", "Чәй йорты" оешмалары, Төркиянең Казандагы консуллыгы, Г.Камал театры, Татарстан Язучылар берлеге һәм Татарстанның Зур симфоник оркестры ярдәм итте.

*yardemtat.ru*





# ИСӘННӘРНЕҢ КАДЕРЕ БЕТКӘНДӘ, ҮЛГӘННӘРНЕҢ КАБЕРЕН НИЧЕК БЕЛЕРГӘ?

**Сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: "Кем гомере озын, ризыгы киң булуны теләсә, туганлык җепләрен ныгытсын", - диде. Туганыңа кылган игелек иң элек үз тормышыңның бәрәкәтен арттыра, мәңгелек йортта әҗер-савап булып кайта. Исән-сау булган якыннарың белән аралашып, кунакка йөрешәсең, табын хәстәрлисең, күчтәнәчләр бирешәсең. Ачык чырай, тәмле сүзеңне бүләк итәсең... Ләкин дөнья тормышы җәннәт түгел, якыннарыңны ничек кенә яратсаң да, көннәрдән бер көнне алар белән аерылырга туры килә. Адәм баласының ризыгы беткәч, әҗәл дигәне аны бу җирдән алып китә. Аллаһка иң сөекле булган зат - Пәйгамбәребез дә якыннарын югалтты. Йөрәгеннән өзеп, күз яшьләре белән ничә баласын, кадерле Хәдичәсен җирләде.**

## Җаннар үз ватаннарына кайталар

Шулай итеп яраткан кешеләребез яныбыздан китеп баралар. Челтерәп агучы чишмә суына карасаң, ул бер су кебек күренә. Ләкин син күргән су инде еракта. Аның яңасы килеп, берөзлексез искесен алыштырып тора. Кешелек елгасы да шулай агуын дәвам итә. Берәүләр килә, икенчеләр китә. Якыныңнан аерылу җиңел түгел, күңелләр тула, күзләр яшьләнә. "Үлем үкенечсез булмый" - диләр, кешене югалткач уйландыра башлый: "Кадерләрен белдемме? Безгә рәнҗеп китмәдеме? Янына ешрак та бара ала идем. Җылы сүзләремне күбрәк тә әйтә ала идем бит"...

Илебездә гасырга якын барган динсезлек афәте безне якыннарыбыз белән мәңгегә аерырга тырышты. "Туганың үлде һәм бетте" дигән көферлек күпме милләттәшләребезнең күңелләрен агулады. Очы-кырые булмаган мәңгелек йортны кечкенә бер чокыр кебек кенә күрә башладык. Газиз туганнабызны җирләгәч,аның белән башка күрешмибез, дип яшәргә тотындык. Ә бит әби-бабайларыбыз 1000 елдан артык үз якыннарын "үлде һәм бетте" дип түгел, бәлки: "Вакытлыча булган дөньядан мәңгелек йортына, хакыйкый ватанына, Раббысы янына кайта. Җәннәттә очрашырга язсын", - дип озаттылар.

Кешенең ахирәт тормышын, кайтасы ватанын инкяр итүе, белмәве зур гаделсезлектер. "Аны кем барып күргән, аннан кем кайткан?" - диләр. Кайтып булса, күпләр кайтыр иде, әмма әҗәл бусагасын бер үткән, кире кайта алмас. Ул яшерен тормышны барып күреп кайтырга да, журналистлар җибәрергә дә  мөмкин түгел. Ахирәт путевкасы бер якка гына. Аллаһ теләсә, фән-сәнагать  үскән саен, Марска да очарлар, әмма ахирәткә барып, аннан кире кайтучылар булмас.

Шөкер, динебез безне соңгы сәфәребез, кайтасы ватаныбыз белән таныштыра.  Ни өчен "ватан" дим, чөнки атабыз Адәм һәм анабыз Һәва бу җир өстенә җәннәттән килделәр, иншә Аллаһ, җәннәткә кайтып китәләр. Аллаһ та Үзенең тугры бәндәләрен җәннәт бакчалары белән көтә. Хәдистә килгәнчә, кеше ана карынында 120 көнлек булганда аның янына күкләрдән махсус фәрештә иңә һәм җан өрә. Шул мизгелдән ул исән кешегә әйләнә. Ризыгы бетеп, әҗәле җитеп үлем фәрештәсе җанын тәннән чыгаргач, тән "мәет" дип атала. Әмма, җан вакытлыча бирелгән тәненнән аерылса да, үзе үлми, юлын дәвам итә. Кеше үлгәч, аның күзләрен йомдырырга кушалар. Чөнки күз ничә ел бергә тормыш иткән җанын эзли, диелә.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә килгәнчә, иман иясе бу дөньядан киткәндә, аның янына, кулларына җәннәт кәфенлекләре тотып, нурлы йөзле фәрештәләр төшә. Соңыннан үлем фәрештәсе килә һәм изге җан тәннән су кебек агып чыга. Янәшәдә утырган фәрештәләр шундук җанны кәфеннәренә төреп (без мәрхүмнең гәүдәсен, алар җанын кәфенлиләр), исле майлар сөртеп, күккә юнәләләр. Күкләрдә аны "гыйллиун" дип аталган махсус урында яздырып, кире тәненә кайтаралар. Бозык бәндә дөньядан киткәндә, аның янына, кулларына ямьсез чүпрәк тотып, кара йөзле фәрештәләр төшә. Үлем фәрештәсе килеп, тешле тимерне юеш йоннан йолкып алган кебек, җанны тәннән тартып чыгара. Янәшәдәге фәрештәләр җанны алып кулларындагы чүпрәккә чорныйлар, шулвакыт җаннан җир йөзендә булган иң күңелсез исләр аңкый башлый. Шул сурәттә фәрештәләр җанны күккә күтәрәләр, әмма аңа күк ишекләре ачылмый...

Җаннар регистрация үткәч, аларны кире тәннәренә кайтаралар. Әмма мәрхүм без белгән дөньяга түгел, бәлки параллель кабер тормышына күчә. (Кайбер гыйлем ияләре "мәрхүм" сүзен кулланырга киңәш итмиләр. Чөнки "мәрхүм" Аллаһының рәхмәте төшкән дигәнне аңлата. Без берәүгә дә андый гарантия бирә алмыйбыз, "мәрхүмнәрдән булсын" дисәк, дөресрәк булыр. Шулай да гадәткә кергәч кулланам инде, догадан китсен.) Кайберәүләр: "Ничә каберне ачып караганыбыз бар, анда черек сөяктән башка нәрсә күрмәдек", - диләр. Күрмәсләр дә, ул бит без яшәгән җирдә түгел. Бүген һавада күзгә күренмәгән нинди генә радиодулкыннар юк. Радио, ТВ, Wi-Fi, GSM, GPS... Радарлы камераларда гына ничә төрле дулкын кулланалар. Шуңа радар ясаучылар белән антирадар ясаучылар һәрвакыт үзара көч сынаша (барысы бер оешмадан да булырга мөмкин). Иң элек ГАИга бер антирадар да күрми торган радар кайта, бераздан кибетләргә аны күрә торган антирадар да кайтып җитә. Әгәр без чикле акылыбыз белән ничә төрле дулкыннарны куллана беләбез икән, Аллаһы тәгалә Үзенең чиксез кодрәте белән берьюлы берничә параллель дөньяларны яшәтә алмыймыни? Без яшәгән дөньяда бездән башка күпме күзгә күренә һәм күренми торган затлар яши. Фәрештәләр, җеннәрне генә алыйк. Күпләр җеннәр дөньясына бөтенләй ышанмый. Ләкин, туганына сихер-зәхмәт тиеп, аны өшкертергә килгәч, үз күзе белән күреп, колагы белән ишеткәч, бик тиз ышаналар.

Шулай итеп, вафат булган туганыбызның тәне гүргә кереп, туфрак булса да, аның тормышы туктамый. Үлем кешене кечкенә һәм кысынкы дөнья тормышыннан киң һәм зур кабер тормышына алып китә. Тормышның бу баскычы шәригатьтә "бәрзах" дип атала. Бәрзах - киртә дигән сүз, ул дөнья белән ахирәтне аера. Бүгенге көндә вафат булган әби-бабайларыбыз бәрзахый тормышта Кыямәтне көтәләр. Кешеләр оҗмах белән тәмугка дөнья бетеп, Кыямәт җиткәч кенә бүленәчәкләр.



## Яңа туган бала кебек

Тар һәм караңгы ана карыныннан якты һәм киң дөньяга чыккан сабый нишләргә дә белми. Ярый янәшәсендә җанын фида кылырдай әти-әнисе бар. Алардан башка бала нишләр иде? Ә таныш булмаган җиргә

аяк басучы мәрхүм нишләргә тиеш? Янәшәдә туганнары да юк. Дөньяда калган балалары һаман: "үлде дә бетте", "аны барып кем күргән?", - дип яшәүләрен дәвам итәләр. "Ташның затлысын куйдым", - дип үзләрен тынычландыралар. Ә бичара мәрхүм ялгызлыкта көтеп ята. Болар кайчан мин яшәгән тормышка ышанырлар икән? Кайчан миңа ярдәм итәрләр икән? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: "Мәетне соңгы юлга өч нәрсә озата, икесе кире кайта, берсе янында кала: гаиләсе, байлыгы һәм кылган гамәле. Гаиләсе дә, байлыгы да кайтып китә, гамәле генә үзе белән кала", - диде.

Туганнарыбызны күпме генә яратсак та, яннарына кереп ятып булмый, ятсак та файдасы тими. Госман ибне Гаффән бер дустының кабере янына килә һәм: "Дустым, хатының калган иде, ул кияүгә чыкты. Өең калган иде анда башкалар тора. Байлыгың калган иде, аны бүлештеләр. Бу минем хәбәрләрем, синнән нинди хәбәрләр?" - ди.

Әйе, кабергә кергәч, кешегә җыйган малы да, салган йорты да куаныч түгел. Өстәвенә анда гомере буе җыйганы өчен җавап тотасы. Исән чакта күңел төшсә, якынына барып сөйләшсәң, утырып чәен эчсәң, рәхәт булып китә. Шалтыратып бала-оныгыңның тавышын ишетсәң дә күңел күтәрелә. Тәһарәт алып намаз укыйсың, кулыңны күтәреп дога кыласың... Әмма мәрхүм боларның барсыннан да мәхрүм.

Әйе, эштәгеләре оешмадан кыйбатлы хәлле венок китерәләр, якыннары каберне затлы чардуган белән әйләндереп, мәрмәр ташын да куялар. Ләкин, чардуган - кабер өстенә басмау, ташы - каберне эзләп табу өчен, безнең өчен кирәк. Еш кына үзара мактанышу өчен кирәк. Ә мәрхүм башка дөньяда, бөтән параллельдә, аңа бу нәрсәләр кирәкми, безне сөендергән аны сөендерми. Әлхәмдүлиллаһ, Раббыбыз рәхимле. Ул безгә газиз туганнарыбызга алар вафат булгач та изгелек кылуыбызны дәвам итәргә мөмкинчелек бирә.

## Мәрхүмнәребез өченниләр эшли алабыз соң?

1. Садака. Исламның бөтен мөгътәбәр галимнәре әйтүенчә, мәет исеменнән "савабы фәләнгә булсын" дип бирелгән садака аңа ирешә. Садаканы мәрхүм өчен чит кеше бирсә дә ярый.

2. Әбү Һурайра тапшыра: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килеп: "Әтием вафат булды, аның байлыгы калды, вәсыятен әйтмәде. Әгәр аның исеменнән садака бирсәм, хаталары кичерелүгә сәбәп булырмы?" - дип сорады. Пәйгамбәребез: "Әйе," - диде (Имам Мөслим җыентыгында).

Садаканы акча белән генә чикләргә ярамый. Әгәр кеше, әҗер-савабы вафат булган әниемә булсын, дип бервр төрле изгелек эшләсә, иншә Аллаһ, файдасы мәрхүмгә ирешә. Мөселман илләрендә күп кешеләр вафат булган туганнары исеменнән коелар казыталар, сулар кертәләр. Сәгд ибне Губадә Пәйгамбәребез салләлләһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: "Әй, Аллаһның илчесе! Әнием вафат булды, аның өчен садака бирсәм буламы?" - дип сорый. "Әйе", - ди Пәйгамбәребез. "Ә нинди садака яхшырак?" - дип янә сорый. Шунда Пәйгамбәребез: "Кешеләргә су эчертү", - дип җавап бирә.

3. Корбан чалу. Корбан чалып, итенең күпмедер өлешен фәкыйрь-мескеннәргә бирү дә садаканың бер төре. Шуңа күрә, Аллаһ ризалыгы өчен, савабы туганыма барсын, дип корбан чалырга да була. Бу төр корбанны Корбан бәйрәме белән чикләргә кирәкми. Чөнки Корбан бәйрәмендә, гадәттә, үзең һәм гаиләң исеменнән чаласың (гаиләңдә вафат булган туганыңны да кертергә мөмкин).

4. Ураза тоту. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килеп: "Әй, Аллаһның илчесе, әнием вафат булды, бер ай тотасы уразасы калды. Аның исеменнән бу уразаны каза кылсам буламы?" - дип сорый. Пәйгамбәребез: "Аның бурычы калган булса, түләр идеңме?" - ди. Ул: "Әлбәттә, түләр идем", - ди. Пәйгамбәр болай ди: "Аллаһ каршындагы бурычын иң элек түләргә кирәк". (Бохари һәм Мөслим риваятьләре).

5. Хаҗ яки гомрә кылу. Җүһәйнә кабиләсеннән бер хатын Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сорау юллый: "Әнием хаҗга барырга нәзер әйткән иде, ләкин нәзерен үти алмыйча бу дөньядан үтте. Аның өчен хаҗ кылырга ярыймы?" Пәйгамбәребез аннан: "Әниеңнең бурычы булса, түләр идең бит. Аллаһ алдындагы бурычны түләү тиешлерәк, хаҗ кыл", - дип әйтә. (Бохари риваяте).

6. Коръән уку. Коръән укуның әҗер-савабы мәетләргә барамы дисәк, бу хакта галимнәр төрле караштa торалар. Әбү Хәнифә һәм Хәнбәли мәзһәбендә, савабы ирешә, диелә. Әмма Мәлики белән Шәфигыйларның күпчелеге ирешми дип аңлаталар. Мәрхүмнәр өчен Коръән аятьләре укылып, әҗер-савабы бүләк ителсә дә, ул диндә нигезе булмаган хорафатларга әйләнергә тиеш түгел. Мәсәлән, 38-40 йәсин чыгулар, акчага Коръән чыгып багышлаулар...

7.Дога-истигъфар кылу. Әлбәттә, исәннәр өчен иң җиңел, мәрхүмнәр өчен иң файдалы гамәл - дога кылу. Елның һәр көнендә, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында үз телеңдә, үз сүзләрең белән Аллаһтан вафат булган туганың өчен сорыйсың. "Йә, Раббым, газиз әткәмәнкәмне Үз рәхмәтеңдә кыл. Аларның хаталарын кичер. Каберләрен нурландыр. Урыннарын җәннәттә кыл. Безне җәннәт бакчаларында очраштыр..."

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер кешене җирләү эшен бетергәч: "Кардәшегез өчен истигъфар кылыгыз (гөнаһлары кичерелүен сорагыз) һәм ныклык сорагыз, аннан хәзер сорау алачаклар", - диде. (Әбү Дауд риваяте).

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә тугры сахабәләре күмелгән Өхүд, Бакыйг каберстаннарына барып, шулар өчен догалар кыла, Аллаһтан кимчелек-хаталарын ярлыкавын сорый иде.

Вафат булган ата-анаң рухына дога кылу өчен ашлар җыю, муллалар чакырту, аерым көннәрне көтү шарт түгел, кулыңны күтәр дә сора, Раббың - кабул итүче.

## Һәркем белергә тиеш...

Һәр мөселман кешесе үзенең вафат булган туганын соңгы юлга озату эшләрен өйрәнергә тиеш. Аның тәнен кадерләп юу, кәфенләү, җеназа уку, ләхеткә индерү... Иртәгә сине тудырган, үстергән атаң, анаң китеп барса, аны кем кулына тапшырырсың? Вафат булган ир туганнарымны, дусларымны үзем юарга тырышам. Ахырда күңелгә рәхәт булып кала. Ничектер, туганыңа соңгы бурычыңны үтәгәндәй, соңгы бүләгеңне биргән кебек тоела.

Кызганыч, көн-төн дөнья куып, якыннарыбызның исәннәрен дә, вафат булганнарын да онытып барабыз. Соңгы вакытта шәһәрләребездә вафат булган әти-әниләрен бөтенләй өйгә дә алып кайтмый башладылар. Янәсе: балалар курерләр, куркып калырлар... Әмирхан Еникинең "Әйтелмәгән васыяте" көндәлек гадәткә кереп бара. Моргта гына юдырып, тизрәк кабергә озатырга тырышалар. Әгәр без - дин кешеләре, өлкән буын моңа каршы тормасак, тиздән бу йолабызны бөтенләй югалтачакбыз. Болай барса, мәрхүмнәребезне моргларда башка милләт кешеләре юу гына түгел, "тиешенчә укып" та җибәрә башларлар. Ә бит динебез вафат булган кешене тиешенчә соңгы юлга озатуны бөтен җәмгыять өчен бурыч итеп куя. Әгәр бер авылда, шәһәрдә мөселман кешесе вафат булып, ул юылып, кәфенләнеп, җеназасы укылып гүргә индерелмәсә, гөнаһысы бөтен кешегә языла. Әгәр арадан бер төркем ул эшне башкарса, гөнаһ бөтен халык өстеннән төшә.

Халыкта: "Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел", - дигән сүз бар. Бүген күп яшьләр авылда торган әби-бабасының айлар буена бер кайтып хәлен дә белмиләр. Туганнарын урамда күрсә танымыйлар. Янәшәңдә исән булган, үзен белдертеп торучы туганыңның кадере бетеп барган заманда, бик ерак тоелучы мәрхүм туганыңның каберен ничек сакларга? Аллаһ ярдәменнән ташламасын.

*Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,*
*Түбән Кама районы мөхтәсибе*



# КИТЕП БАРЫШЛЫЙ

**Кайчан да булса Аллаһы Раббыбыз яраткан якыннарыбызны үзенә ала. Һәрбарчабызга зур кайгы килә, кояшның нурын, көннең матурлыгын, ризыкның тәмен сизми башлыйбыз. Бу - бик тә авыр хушлашу.**

Үлем ул - кешенең гәүдәсеннән җаны аерылып чыгу. Интекмичә җаны чыгучылар бик аз, күпләр зур авыртулар кичереп, хәтта сөйләшү, хушлашу сәләтен югалтып китә.

Әгәр үләргә яткан кеше акылында булса - аны әлләни интектермичә: "Ләә иләәһә илләллаһ",- дип әйттерү бик яхшы. Әйтә алмаса, ул кеше янына утырып, шушы сүзләрне аның колакларына пышылдарга кирәк. Ахыргы ишеткән сүзләре шәһадәт кәлимәсе булуы тиеш.

Шулай ук үлеп баручыга Коръән уку һәм аны тыңлату бик саваплы. Күбрәк "Фатиха", "Йәсин" сүрәләрен укырга кирәк. Әгәр укучылар булмаса, кассета-дисктан яки интернет челтәреннән Коръәнне тыңлату да тыелмаган. Чөнки Кәламе шәрифтәге шифалы аятьләр үлем газабын күпмедер дәрәҗәдә җиңеләйтә.

Туганыгыз кырыенда җыелышып, аны сөйләштереп яки кинодагы шикелле тегесемонысы белән саубуллаштырып маташа күрмәгез. Бу - бик начар гамәл, аны интектермәгез! Хәзер моның вакыты түгел, мәңгелеккә күчену вакыты. Монда буш дөнья сүзе булырга тиеш түгел.

Бу авырлык һәрбер гаиләгә, һәрбер кешегә килә, берәү дә моннан азат түгел. Гомер буе кемнедер каршы алабыз, кемнедер озатабыз...

Бу вакытта безнең төп бурычыбыз - вафат булган кешенең җанын куркытмау. Чөнки җаннар юкка чыкмый, алар - исән һәм бар нәрсәне ишетеп вә тыңлап торалар. Бакый дөньяга көн саен йөри торган булсак, ул безнең өчен бер дә куркыныч урын булмас иде. Ләкин ахирәткә баруыбыз фәкать бер генә мәртәбә. Шуңа да үзе белән нәрсәләр булыр дип мәет бик нык курка. Әгәр үле гәүдә кырыенда үксеп-үксеп елый башласак, вафат булган кешенең җанын куркытып, аңа тагын да зуррак авырлык китерергә мөмкинбез.

Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм баласы вафат булган хатын янына килеп, аны юата:

- Курык Аллаһыдан (артык елама), сабыр ит, - ди.

Теге хатын аның Пәйгамбәр икәнен танымыйча:

- Сөйләмә! Синең балаң түгел, минеке үлде, - дип каты итеп җавап кайтара.

Әмма соңыннан аңа кем белән сөйләшкәнен аңлаталар һәм ул, хатасын танып, Аллаһының рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп гафу сорый.

- Бәла килеп төшкән сәгатьтә сабырлык кылу - иң күркәм сабырлыктыр, - дип җавап кайтара аңа Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм (Бохари риваяте).

Шуңа күрә, хөрмәтле мөселман кардәшләрем, мәет каршында кычкырып елый күрмәгез, ул юкка чыкмады, бетмәде. Ул сезгә карап, сезнең һәр сүзегезне тыңлап тора. Игътибарлы булыгыз!

Кеше вафат булгач, аны озак күммичә тору ислам диненә тыелган. Без мәетне җир өстендә никадәр озаграк тотсак - аны шулкадәр озаграк интектерәбез. Балык судан һавага чыгып ничек азапланса, вафат булган кешенең дә җаны җир өстендә шулай ук авырлыклар чигә. Ул тизрәк күмелергә, үзенең мәңгелек йортына күчәргә һәм бу дөньядан тизрәк котылырга омтыла.

**МӘЕТ ЯНЫНДА КАБАЛАНЫП ЙӨРГӘНЧЕ ШУШЫ КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ ТӘРТИПЛӘРГӘ КҮЗ ТӨШЕРЕГЕЗ:**

1. Мәетне, аяклары белән кыйблага борып, аркасына яткырыгыз.

2. Күзләрен, авызын йомдырыгыз.

3. Корсагы күбеп китмәсен өчен авыррак әйбер куегыз.

4. Полицияне дәшегез, үлем турында расланган кәгазьне алыгыз.

5. Табибларны чакыртып, алардан үлем турында таныклык алыгыз.

6. Туганнарыгызны, мәет юучыларны, мәхәллә хәзрәтен дәшегез.

7. Каберлек турында белешегез. Җеназаны кайда вә ничәдә укырга икәнен фикерләшегез. Туганнарыгызны һәм башка халыкны шул вакытка чакырыгыз.

8. Мәетне юа, кәфенли башлагыз.

9. Ишегалдында тәһлил һәм дога кылырга урын әзерләгез.

10. Әҗәт-бурычлары турында белешегез (бу бик әһәмиятле).

11. Җеназа намазын башкарып, мәетне озатыгыз.

12. Зиратта мәет күмүдә халыкны оештырыгыз.

*Хәбир хәзрәт ХАНОВ,*
*Чирмешән мәчете имам-хатыйбы*
*("Шура" журналыннан алынды)*

# НИЯТ КҮРКЕ – ЭШ-ГАМӘЛ

**Шатлыклы мәшәкатьләре, үсеш-үзгәрешләре белән бара тормыш. Узган гасырның 90 нчы еллары башында Казаныбызда һәм татарлар яшәгән төбәкләрдә бер-бер артлы мәчетләр салынуына шаһит буын без. Күз алдыбызда азаннар әйтелеп, тантаналы шартларда халкыбызны иманга өндәп мәчетләр ачылу әле кайчан гына кебек?! Тоташ җитмәүчелек шартларында, төзелеш материалларына кадәр кем кайдан һәм ничек юнәтә ала, шулай күмәк көч белән, һәм шактый киртәләрне узып, авырлык белән төзелгән мәчетләр бүген инде ачылуларына 20-25 ел тулуны билгеләп үтәләр. Яшерен-батырын түгел, халык акчасына, гади хезмәт кешеләре көче белән калыктылар алар.**



Күз алдыбызда буыннар алышынды. Дин ирегә ачылуга, утлар-сулар кичкән өлкән буын имам-мәзин вазыйфаларына кереште, шушы җаваплылыкны ышандырып алдылар. Аллаһ рәхмәте, бүген аларны яшьләр алыштырды. Димәк, данлыклы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең дә, гыйбрәтле тарихлы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәнең дә кадрлар әзерләү буенча тырышлыгы бушка китмәгән. Шөкер, имам-хатыйб вазыйфасы хәзер 25-35 яшьлек ир-егетләребез иңендә. Бер үк вакытта күпчелеге Россия ислам институтында тырышып дөньяви белемнәр алган дин әһелләребез өчен сөенеп туймаслык.

Журналистлык һөнәрем буенча Казанның мәчет-мәдрәсәләре тормышы белән кызыксынып торсам да, таныш булсам да, соңгы биш елда Казанда яшәмәдем. Сагынганда, дин кардәшләрем белән очрашу-аралашу теләге көчәйгәндә Казаныма кайткач, якын-тирәдәге мәчетләрне йөреп чыгармын, дигән теләгем бар иде. Шушы биш ел эчендә шактый яңалыклар, куанычлы үзгәрешләр булган икән.

Иң беренчесе - башкалабызның байтак мәчетләрендә намазга килүчеләрнең фарыз залларына гына сыймый башлавы. Бу бит инде мөселманнар сафы үсүен, туры юлга омтылучылар сафының яшәрүен күрсәтә! Хәтерем ялгышмаса, биш-алты ел элек кала үзәгендәге Нурулла мәчете җомгага килүче ир-атларга урын җитмәгәч, хатын-кызлар залын да бу изге көнне аларга бирергә кирәк дип тапты. Әлеге мәчеткә күп еллар җомга вәгазе тыңларга йөреп ияләнгән без хатын-кызлар күңелендә баштарак ризасызлык булса да, бу хәл белән килештек. Яңа, заманча йортлар чолганышында калган Казан нуры мәчетендә дә шул ук хәл икән: җомгага дип килгән ир-ат җәмәгате фарыз залына гына сыешмый башлагач, аскы каттагы хатын-кызларга тәгаенләнгән бүлмәләргә төштеләр. Тәүге сабак алган, әлифнең таяк түгеллегенә төшенгән, күңеләмә аеруча газиз Нур ислам мәчетенә баргач та, шул ук күренешкә шаһит булдым: ачып кергәннән бирле хатын-кызлар намаз укый торган залны җомга көннәрендә ир-атларга биргәннәр дә, хатын-кызларны өске катка, тагын да иркен урынга күчергәннәр. Сөбханаллаһ, үзем күргән әлеге мәчетләрдә җомга вакытында алма төшәр дә урын юк!

Мине сөендергән икенче яңалык: әлеге дә баягы намазга йөрүчеләр, мәчеткә тартылучылар саны күзгә күренеп үсү белән, моннан 20-25 ел элек ачылган иман йортларының "кечерәеп" калуы. Нагорный бистәсендәге Иман нуры һәм Гадел мәчетләрен хәзер танырлык түгел. Бирегә юл салган мөселманнар санын исәпкә алып зурайтылганнар, тагын да күркәмләндерелеп, санаулы айлар эчендә мәһабәт бәйтуллаһлар булып калыкканнар. Сер итеп кенә әйтим: тиздән алар тантаналы төстә ачылырга, бу сөенечләрен киң җәмәгатьчелек белән уртаклашырга әзерләнәләр. Кем ничектер, әмма бу очракта шушы олыгаем эшләрне тартмый-сузмый башкарып чыгарлык иганәчеләр, төзүчеләр таба алган һәм ният-максатларын бергәләп гамәлгә куйган Нияз хәзрәт Закиров, Рөстәм хәзрәт Бакировларның бу тырышлыкларын башкаларга үрнәк итеп куймый булдыра алмыйм. Булдырдыгыз егетләр!

Рамазан, Ризван һәм Казан читендәге Фатиха мәчетләреннән дә куанып кайттым. Өлкән имамнар янында имамәтчелек мәктәбе үтеп, аларның бай тәҗрибәсен һәм хәер-фатихаларын алып калган Солтан хәзрәт Морадыймов, Алан хәзрәт Панарин һәм Фәннур хәзрәт Зәйнуллиннарның мәхәлләдәшләре белән уртак тел табып, тату, иплe эшләүләренә шаһит булдым. Соңгы ике елда алар имам-хатыйб вазыйфасы өстенә бик күп һөнәрләрдән торган төзүче-реконструкцияләүче вазыйфасына алынып, мәчетләрендә затлы ремонт үткәргәннәр, уңай шартлар булдырганнар.

Бөтентатар башкаласы булып торган, еракларга даны таралган Казаныбыз - азанлы, нурлы, моңлы башкалабыз мине шулай куандырды. Түбәләре күккә ашкан торак комплекслы, шул ук вакытта борынгылыгын да саклаган калада иман йортларыбыз да ерактан ук үзенә дәшеп, балкып тора. Гүя алар заманча төзелешләрне кабатланмас архитектура үрнәкләре буларак тулыландыралар.

***Вәсилә РӘХИМОВА,***
***журналист***

***

*Күптән түгел генә каләмдәшебез Вәсилә апа Рәхимова үзенең 60 еллык юбилеен билгеләп үтте. 1995 елдан бирле "Иман", "Ватаным Татарстан", "Шәһри Казан", "Мәдәни җомга", "Татарстан яшьләре", "Мөслимә", "Ислам-инфо" газеталарында аның дин-исламга, әдәп-әхлакка кагылышлы язмалары даими басылып килә. Вәсилә апа 2007 елны Татартан мөселманнары Диния нәзарәтенең массакүләм мәгълүмат чаралары арасында мөселманнар тормышын яктырту буенча уздырган беренче конкурсында "Татарстанда рухи тормыш турында дөньяви массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы материал" номинациясендә, узган ел исә "Каләм" конкурсында җиңүче булды. Ул күренекле татар имамнары турындагы берничә китап авторы да. Без аңа исәнлек-саулык, иҗади уңышлар телибез.*

### МӘЧЕТКӘ КЕРГӘНДӘ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

***Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм мәчеткә кергәндә әлеге доганы укый торган булган: "Әгүүзү билләәһи-ль газыйм үә биуәҗһиһи-ль кәрим үә сүльтаниһи-ль кадиим минә-ш шәйтаани-р раҗиим. Әлхәмдү лилләһ. Аллаһүммә салли үә сәллим галәә Мүхәммәдиү үә галәәә әәли Мүхәммәд. Аллаһүммә гъфир лии зүнүүбии үәфтәх ли әбүәәбә рахмәтик"***

**МӘГЪНӘСЕ:** *"Ләгънәт төшкән шайтаннан Аллаһ Раббымның чиксез көч-куәтенә сыенам. Аллаһы Тәгаләгә мактау булсын! Йә, Аллаһым! Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның кавеменә рәхмәт һәм сәлам кыл. Йә, Аллаһым! Гөнаһларымны гафу ит, мәрхәмәт-шәфкать ишекләреңне минем өчен ач!" ("Әл-Әзкәр": 32).*

# КОРЪӘН УКУНЫҢ

**Аллаһы Раббыбыз Коръәни-Кәримдә әйтә: "Кеше ислам диненә ярашлы итеп яралтылды". Ягъни ислам дине һәм кеше Аллаһ тарафыннан берберсе өчен яралтылганнар, дин кешегә зыян китерми, киресенчә, файда гына бирә. Шулай булмаса, болай яралтылуның мәгънәсе булмас иде.**

Чыннан да, динебездәге күп гамәлләрне алып карасак, аларның кешегә рухи яктан да, физик яктан да файдалы булуына ышанабыз. Мәсәлән, иң олы гыйбадәт булган намаз кешене, Аллаһы Тәгалә әйткәнчә, фәхеш эшләрдән, гөнаһка батудан саклый (рухи саулык). Әмма ул бер үк вакытта тәнгә гимнастика да булып тора (физик сәламәтлек). Уразаны алсак, ул да файда бирә - Раббыбыз каршында тәкъвалыгыбызны арттыра, шуның өстенә тәнебезнең күзәнәкләрен төрле пычраклардан арындыра.

Ислам динен Коръән укудан башка күз алдына китереп булмый. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Без Коръәндә мөэминнәргә шифа һәм рәхмәт индерәбез" (17/82). Коръән укыганда кешенең рухи үзгәреш кичерүен беләбез: ул аятьләрдә язылган хикмәтле сүзләрнең мәгънәләре турында уйлана, Аллаһның хакыйкатен аңлый һәм рухи яктан савыга башлый. Әмма Раббыбыз "рухи шифа гына индерәбез" дип әйтми бит. Димәк, бу сүзне киңрәк мәгънәдә аңларга кирәк. Ягъни "шифа" дигән сүз рухи шифаны да, тән шифасын да үз эченә ала. Ачыграк итеп әйткәндә, Коръән укучы кеше рухи савыгу белән беррәттән физик савыгу да кичерергә тиеш.

Ә физик савыгу Коръән укучы кешегә ничек килә соң? Сорауга җавап биргәнче, башта медицина өлкәсендәге белемебезне бераз гына яңартып алыйк. Урта мәктәптә без кешенең тән төзелешен өйрәндек һәм беләбез: кеше организмында йөрәк-кан тамырлары системасы гаять мөһим роль уйный. Йөрәк-шушы системаның үзәге. Кислород белән баетылган кан аорта дип аталучы юан артерия аша йөрәктән чыга. Аннары ул кечерәк юанлыктагы артерияләргә, аннары тагы да нечкәрәк артериолларга тарала, ә алардан капиллярлар дип аталучы бик нечкә кан юлчыкларына барып керә. Капиллярлар - кан агып килүнең соңгы пункты. Капиллярдагы кан үзендәге кислородны һәм туклыклы матдәләрне тән тукымаларына һәм органнарга тапшыра да, күзәнәкләр эшләп чыгарган углекислый газны алып, вена буйлап кире йөрәккә таба агып китә. Капиллярларда кан йөреше әйбәт булганда, тукымалар да, органнар да кислородны һәм туклыклы матдәләрне җитәрлек күләмдә алалар һәм нормаль эшлиләр. Ләкин кеше олыгайган саен капиллярлар тарая бара, алардагы кан йөреше акрыная, тән тукымалары һәм органнарга килә торган кислород белән туклыклы матдәләр дә азая. Кислород җитмәгәнлектән, күзәнәкләр үз функцияләрен тулысынча үти алмыйлар. Ә бик нык кислород ачлыгы күзәнәкләрнең массакүләм үлүенә - әгъзаларның инфарктына китерә. Бу йөрәккә генә түгел, баш миенә дә, башка органнарга да кагыла. Табигый ки, дәвалау чаралары кан йөрешен яхшыртуга юнәлдерелергә тиеш. Кан тамырларын киңәйтүче табигый матдә - кандагы углекислый газ. Димәк, артериоллар һәм капиллярларның даими рәвештә тарайган хәлдә булуларының сәбәбе - углекислый газның җитәрлек концентрациядә булмавы.

Сәламәт кешенең организмында артериоллар белән капиллярларның нормаль киңлеге һәм үткәрүчәнлеге кандагы эрегән углекислый газ - CO хисабына саклана. Бу матдә, углеводларның окисьләшү продук-

ФРОНТОВИК ХАТЫ

# "Уйланмаган әти бар дип, эзләнмәгән дә"

**Әтисе Йосыпов Сәләхетдин Йосыф улының, 73 ел элек, 1942 елда сугыштан әнисе Әминәгә язган хатын тотып уйга калган Данил абый Сәләхетдинов әнә шулай дип көрсенә. Ә хаттагы юллар йөрәкне меңгә телә.**



## "Туйганчы ипи ашап утырсаң иде"

"Җырак җирләрдә хали, бер күреп сөйләшергә зари ибдәшең Сәләйдән ибдәшем Әминәгә бик сагынып, бик саргаеп бик күптин күп сәламнәремне язып калам һәм кызларым Наилә белән Рәхиләгә бик сагынып, бик саргаеп бик күпдин сәлам, һәм улларым Илдар белән Данилгә бик сагынып, бикләр саргаеп бик күп сәлам, һәм Нәсимәгә бик сагынып, бик саргаеп бик күп сәлам, әби белән Флүргә бик сагынып бик күп сәлам, һәм Галимәгә балалары белән бик сагынып, бик саргаеп бик күп сәлам, һәм күршеләргә аермаенча бик сагынып, бик саргаеп бик күп сәлам.

Сәлам соңында үзем шул больниста таза-сау ятам әле. Ул тарафда сезне дә сәламәт дип беләм. Бу да мәгълүм булсын. 17 мартта язган ике хатыгызны бер көнне алдым. Утызынчы мартта үзем 30/III да, 31/III да ике көнне ике хат салдым. Кайчан тазарып чыгасы көнне белмим. Шулай булгач, минем бу больнистан чыгам дигән хат килгәнче хат язып салыгыз. Яз көне су вахытларын шушында уздырып булса, әйбәт булыр иде. Сезнең хәлләрне белү өчен бик кайгыра идем. Хат алмаганга бик күптән иде бит. Ярты еллап хат алмый тордым. Сезнең ашарлар начар микән, балалар ачялангач түгел микән дип беләсем килә иде. Сезнең хәлләр әйбәт икән, Аллага шөкер икән.-

Минем хәлләр бик шәп түгел. Өйгә кайтып өстәл янына утырып, үзем кисеп, туйганчы ипи ашап утырсаң иде. Үзегезнең тамак туйгач, мине исегезгә төшерегез. Күрдем инде. моннан соң тагынниләр күрәсе язгандыр. Тазарып тагы керсәм, сезнең балаларның бәхете бик зур булса гына исән чыгарым инде. Ичмаса тәмәке дә юк. Бер ай инде бирмиләр. Пачкасы 100 сум, ... 60 сум. Фазылҗан кайда? Адресы ничек? Хәбиб, Гыйззәт, Гарифлар, Фатихларның хатлары киләме?

Бу да мәгълүм булсын. Мин күптән бер хат эчендә сезгә справка җибәргән идем инде. Әрмиядә булганлыкка, декабрь айларында. Шуны алдыгызмы, юкмы?.. Авылларны, күрше авылларны түгел, Арча районыннан бер кеше күргәнем юк һәм татар. Урыслар - бар да. Безнең монда бик суык әле, сездә ничектер.

Хуш сау булыгыз, хәер-догадан ташламагыз. Балаларны дәрестән калдырырга карама.

ТАССР, г. Казан, ст. Арск, район Арский, дер. Н....Юсупова Амина... от Ивановская область"

## "Сәләй" дип йөрткәннәр

Саргаеп кызгылт-көрән төскә кергән кәгазь битенә гарәп телендә язылган хатның тәрҗемәсе бу. Ә хаттан "кан тама", кулны пешерә. Олы Әтнәдә гомер итүче, үзе дә сиксәнгә караган Данил Сәләхетдин улының кичерешләрен аңларга тырышып карыйм...

- Сәләхетдин исемле булган әти, Сәләй дип йөрткәннәр аны. Хатына үзе дә Сәләйдән дип язган. Әти 1903 елда Арча районының Әзәк авылында туган. Аны сугыш башлангач та алганнар, пехотинец булган, ул фронтка киткәндә мин шул 1 яшьтә 8 айлык булып калганмындыр инде. Әнием Әминә 4 бала белән әтине озаткан. Ниләр кичергәндер, үзенекен үзе белгәндер, без 4 бала исән-сау үстек. Әтигә хат язган вакытта әнинең тыныч тормыштан калган, саклап тоткан запаслары булгандыр, әти безнең тормышка кызыгырлык булгач, без ул вакытта әти кебек үк ачтан интекмәгәнбез әле. Соңрак ачлык безне дә читләп үтмәгән. Үскәнбез, әнинең тырышлыгы белән ачтан үлмәгәнбез. Апайлар исән түгел инде. Әни үзе 1982 елда вафат булды. Гомер буе әтине көтеп яшәде, юклыгы белән килешәсе килмәде. Бу хатны үзенең дини китаплары, догалары арасында саклаган, көнгә ничә укыгандыр... Әнидән соң Рәхилә апайга күчкән бу хат. Апай Комыргуҗа авылында яшәп үлде. Безгә апай вафатыннан соң, узган ел килде. Хат безнең телдә язылмаган, без аны укытыр өчен бик күп кешегә күрсәтеп карадык, төрекләр дә укый алмады, гарәпләр дә, инде укып булмас дип уйлаган идек, күптән түгел энекәшнең дустының хатыны, фән докторы ул, Казанда яши, укып тәрҗемә итеп бирде. Хат борынгы гарәп телендә язылган булган, ул телне белүче ике генә белгеч калган, берсе - Казанда, икенчесе Мәскәүдә, ди. Исемен хәтерләмим инде,- дип туктап калды Данил абый.



Хәтер кеше белән бергә үлә, ә менә Сәләхетдин абыйның хаты безне аяусыз елларның чынбарлыгына алып китә. "Әти бар дип уйланмаган инде, эзләнмәгән дә. Шушы хат килеп чыккач уйландыра башлады. Аз сөйләшкән, надан булмаган әти. Язган хатын укыгач, әчлек күргән дип җәлләдем, тартырына тәмәкесен дә бирмәгәннәр. Бу соңгы хаты әтинең, 1942 елның мартында язгандыр ул аны, Марига кайтучыга биреп җибәргән булырга тиеш. Госпиталь Муром шәһәреннән 80 км ераклыкта урнашкан булган, анысын белештек, Мәскәүне утка тотарга тиешле 400 самолетның бер өлеше әти яткан госпиталь өстенә бомба ташлап киткәндер, дигән фараз бар. Арча районының "Хәтер" китабында бар әтинең исеме. Күмелгән урынын ачыклап бетерсәк, каберенә дә барып кайтырга исәп бар. Шулай гына булса да күрешәсе килә әти белән", - ди Данил Сәләхетдин улы. Кабул булсын иде ул теләк.

*Сүрия МИНГАТИНА*

# ТӘНГӘ ШИФАСЫ

ты буларак, организмның һәрбер күзәнәгендә эшләнә. СО иң соңыннан үпкәләр аша организмнан чыгарыла. Әмма үпкәләргә таба барганда ул берникадәр вакыт кан составында була, шул чакта кан тамырларының киңлеген табигый көйләүче ролен үти, ягъни аларның тараюын тоткарлап тора.

Углекислый газ артериаль канда сизелерлек кимегәндә кече кан тамырлары шактый тарая. Аларның тараюы тән тукымалары һәм әгъзалар аша кан үтүен азайта һәм аларда ишемия китереп чыгара. Ә ишемиянең хроник рәвештә саклануы бу әгъзаларның авырый башлавына сәбәп була. Дару эчү бу органнарны дәваламый, авыруның сәбәбен бетерми, ә бәлки авыртуны вакытлыча баса гына.

Табиблар арасында эзләнүче, дәвалауның яңа ысулларын кулланучы кешеләр дә бар. К.П.Бутейко, мәсәлән, баш һәм йөрәк авыруларын дәвалауның яңа алымын куллана. Әлеге алым сулыш алуны берничә минут буе туктатып торудан гыйбарәт. Бу очракта авырту кече кан тамырларының киңәюе нәтиҗәсендә бетерелә, чөнки аларның киңәюе йөрәккә төшкән авырлыкның һәм кан басымының кимүенә китерә.

Бу очракта артериоллар ни сәбәпле киңәя? Организмга бит читтән берни дә кертелми. Димәк, артериолларның тышчасына организм үзе эшләп чыгара торган матдә тәэсир итә. Бу матдә - углекислый газ. Сулыш алуны (төгәлрәге - үпкәләрдән һава чыгаруны) тоткарлау артериаль канда углекислый газның артуына китерә. Канда углекислый газ күбәюгә үк артериоллар киңәя.

Кеше яшь чагында чагыштырмача күп хәрәкәтләнә һәм аның сулыш алуы физиологик нормаларга туры килә. Ләкин олыгая төшкәч, стресслар һәм аз хәрәкәтләнү аркасында аның сулыш алу ешлыгы арта һәм 50-60 яшьләргә җиткәндә инде күпчелек кешеләрдә нормадан 2-3 тапкыр артып китә. Үпкәләрнең артык еш сулавы артериаль каннан углекислый газның күпләп чыгарылуына китерә. Артериаль канда углекислый газның гадәттән тыш кимүе атериолларның даими рәвештә шактый тараеп торуына китерә һәм кислород белән туклыклы матдәләрнең җитмәве сәбәпле ахыр чиктә органнар авырый башлый.

Канда углекислый газның оптималь концентрациясен саклау - бик күп авырулардан котылуның зарури шарты һәм бердәнбер ысулы. Ә моның өчен, инде әйтелгәнчә, сулыш алуны сирәгәйтергә кирәк. Минем уемча, Коръән укыганда кулланыла торган тәҗвид кагыйдәләре нәкъ менә шушы процессны тормышка ашыра да инде. Коръәнне тәҗвид кагыйдәләре белән укучы кеше тирән итеп сулыш ала да, үпкәләрендәге һаваны аз-азлап чыгарып аятьләрне укый, тыны бетәр алдыннан туктап сулыш ала, аннары тагын укып китә. Ул укыган чакта сулышын гадәттәгедән күпкә сирәгрәк ала, үпкәләреннән һава чыгуны тоткарлый, шул чакта аның артериаль канында углекислый газ концентрациясе арта, ә углекислый газ, үз чиратында, кан тамырларының тараюын кисәтә, кислородның һәм туклыклы матдәләрнең җитәрлек күләмдә килүен һәм авыру әгъзаларының савыгуын тәэмин итә. Шуңа күрә Коръәнне тәҗвид кагыйдәләрен кулланып укуның безнең өчен никадәр әһәмиятле икәнен без аңларга тиешбез. Һәм Аллаһның бөек Китабын никадәр күбрәк укысак, шулкадәр сәламәтрәк булырбыз, иншә Аллаһ. Әлбәттә, тәҗвид кагыйдәләренең бөтен хикмәте дә бардыр. Анысын Аллаһы Тәгалә генә белә.

*Рәшит ФӘЙЗРАХМАН,*
*Мамадыш районы,*
*Ишкәй авылы*

# ЧЫН ТОРМЫШ ТУЙДАН СОҢ БАШЛАНА

**Ничә яшендә булса да, кайда укыса-эшләсә дә, нинди генә дәрәҗәләргә ирешсә дә, кеше гаилә җылысын тоймаса, тулы бәхетне татымый торгандыр, мөгаен. Балачакта туган йорт җылысын тоеп, әти-әни кочагында җилдавылдан имин яшәгән кеше генә, үсеп җитеп, үзе кабызган гаилә учагын еллар дәвамында саклап яшәргә тырышачак.**



Бәхетле һәм нык гаиләнең нигезе - әлбәттә, никах. Бүгенге көндә кайбер яшьләребез никахның әһәмиятен аңлап бетерми. "Гражданский брак" бик популярлашып китте. "Берәр ел бергә яшәп карыйк та, никахны аннары укытырбыз. Яшәп китә алмасак, таралышырбыз", - дип фикер йөртәләр. Аллаһы Тәгаләнең кануннарын инкарь итеп башланган гаилә тормышы берничек тә бәхетле була алмый.

Бу, әлбәттә, ислам динендәге яшьләргә кагылмый, ләкин алар арасында соңгы елларда яшерен никахлар киң таралыш алды. Әбү Хәнифә мәзһәбендә вәлинең ризалыгы фарыз түгел, дигән фикергә таянып эш итәләр. Ике шаһит табалар да, әти-әнигә әйтмичә генә никах укыталар. Ә бит никахның асылы иң беренче чиратта Аллаһ Раббыбыз каршында, аннары барлык кешеләргә "без бергә" дип игълан итүдән гыйбарәт. "Никах" һәм "яшерен" дигән сүзләр, гомумән, янәшә тора алмый шул, әти-әни фатихасыннан башка корылган гаилә тиздән чәлпәрәмә килә.

Күп әкиятләр "өч көн гөрләтеп туй иткәннәр, шуның белән әкият тә беткән" дип тәмамлана. Чыннан да, шаулатып никах-туйларны үткәреп җибәргәннән соң әкият бетеп, чын хикәят башлана. Гел әкияттәге кебек матур итеп кенә яшәрбез дип хыялланган яшьләр шушы "хикәят"кә әзер түгел. Статистика буенча, бүген өйләнешкән парларның 80%ка якыны аерылыша. Иң төп сәбәп холыклар туры килмәү белән аңлатыла. Аның 100% туры килүе мөмкин дә түгел юкса.

Бәхетле гаиләнең тагын бер сере - бер-береңне ничек бар шулай кабул итү. Гаилә тормышын алып барганда сабырлык һәм гафу итә белү дә бик кирәк. Дүрт аяклы ат та абынган кебек һәркем хаталана, ялгыша, беркем дә кимчелекләрдән пакь түгел: уйланылмаган, кирәкмәс сүзләр дә әйтелә, ялгыш гамәлләр дә кылына. Тормыш гел без уйлаганча гына бармый шул: сөенеч-шатлыкларны көтелмәгән борчу-хәсрәт алыштыра. Менә шул вакытта гаилә сынала башлый. Килгән авырлыкларны сабырлык белән, бер-береңә булган хөрмәтне югалтмый үткәреп җибәргәндә генә гаиләне саклап калып була.

Ислам дине безгә бәхетле һәм ышанычлы гаилә кору серләрен тулысынча ачып бирә. Коръән аятьләрендә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә ир һәм хатынның вазифалары ачык күрсәтелгән. Ир - гаилә башлыгы, гаиләне барлык кирәк-ярак белән тәэмин итү, хатынын хөрмәтләү, яклау, аның намусын һәм сәламәтлеген саклау, балаларны тәрбияләүдә катнашу - аның бурычы. "Ир - баш, хатын - муен" дип әйтә безнең халкыбыз. Муен кая борса, баш шунда карый. Шуңа да хатын акыллы, зирәк, яхшы киңәшче булырга тиеш. Ул гаилә тормышын көйләп торучы, аңа дөрес юнәлеш бирүче. Хатын-кыз өстендэ бик зур җаваплылык ята, беренчедән, ул гаиләнең рухи тотрыклылыгы өчен җавап бирсә, икенчедән, өйдәге тавык та чүпләп бетерә алмаслык эшләр аның өстендә, гәрчә шәригать буенча бу турыдан-туры анын вазифасы булмаса да.

... Балачагымны искә алуга тәрәз төпләрен тутырып үскән гөлләр, әни кулы белән пешерелгән табын тулы тәмле ризыклар күз алдына килә. Әниләребез, әбиләребез кебек без дә гаиләбезгә бар күңел җылыбызны биреп яши алсак иде. Безнең гомер сикәлтәле озын юлны хәтерләтә. Йөрәгебез мәхәббәт белән тулы булса гына шушы юлны матур итеп үтә алырбыз. Иң беренче чиратта, Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә һәм Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата ярату, аннары газиз әти-әниләребезне, сайлап алган парыбызны, үзебез тудырган балаларыбызны, якыннарыбызны ярату, хөрмәт итү тиешле. Шулай булганда гына тормыш сынауларын тиешенчә үтеп, ике дөнья бәхетенә ирешә алырбыз, иншә Аллаһ.

*Айгөл ШАКИРОВА, Казан*

## ҖӘННӘТТӘ АВЫРГА УЗУ, БАЛА ТАБУ БУЛАЧАКМЫ?

**СОРАУ.** ***Аллаһы Тәгалә хатын-кызны бу дөньяда авырга уза, бала таба һәм бала тәрбияли торган зат итеп яралткан. Ә җәннәттә авырга узу, бала табу, аларны үстерү булачакмы?***

**ҖАВАП.** "Әд-Дүррел-Мохтәр" һәм "Ән-Никах" китапларында болай диелгән: "Безнең өчен никах белән иманнан тыш гыйбадәт юк. Алар Адәм галәйһиссәлләм заманыннан башлап бүгенгәчә килгән һәм җәннәттә дә дәвам итәчәк".

Ә "Рәддел-Мохтәр" китабында Бине Габидин бу теманы түбәндәгечә аңлата: "Аның сүзе (ягъни Дүррел-Мохтәрдән: безнең өчен башка гыйбадәт юк): Бине Нөҗәймнең "Әл-Ашбахван-Нәзаир" китабында да шулай дип әйтелгән, ләкин бу сүзләр бәхәсле. Чөнки никах - фани дөнья өчен гыйбадәт, ул мөселманнарның саны артуга китерә һәм пакьлек (зинадан тыелу) һ.б. билгесе булып тора, ә болар җәннәттә юк.

Хәдистә китерелә: "Җәннәт әһелләре өчен балалар (аларның туувы) булмас.

Икенче бер хәдистә исә: "Әгәр мөэмин җәннәттә бала теләсә - авырга узу, бала табу һәм аның үсүе бер сәгатьтә булачак", - диелә.

Бу яхшырак, чөнки имам Тирмизи бу хәдисне хәсән-гариб дәрәҗәсенә ия ди. Җәннәттә зикер һәм шөкер дә бу дөньядагыдан күбрәк, чөнки Аллаһы колының җәннәттәге халәте - туктаусыз, армыйча, көне-төне тәсбих әйткән фәрештәләрнең халәте кебек булачак.

Нәтиҗәдә гыйбадәтнең бу төре җәннәттә тәклиф (йөкләнгән бурыч) булып тормаячак, бәлки табигый хаҗәт булачак; чөнки Аллаһыга хезмәт итү ул - ләззәтле һәм лаек гамәл һәм болар Аңа якынайган саен арта гына бара.

## ИР БЕЛӘН ХАТЫН ТАЛАКТАН СОҢ КАБАТ КУШЫЛА АЛАМЫ?

**СОРАУ.** ***Ир кеше хатынына өч тапкыр "талак" дип әйтсә, аннан соң бер ел вакыт аралыгында икесе дә яңа гаилә кормаган булса, алар яңадан бергә яши башлый аламы?***

**ҖАВАП.** Хәнәфи мәзһәбе буенча, талактан соң хатын-кыз никадәр вакыт үтүенә карамастан, башка беркемгә дә кияүгә чыкмаган булса, аңа үзенең элекке ире белән кабаттан бергә яши башлау тыела. Коръәни-Кәримдә әйтелгән: "Әгәр берәү хатынын өч мәртәбә талак кылса, ул хатын, икенче иргә никахланып аннан аерылганчыга чаклы, беренче иренә хәләл булмас" ("Әл-Бәкара", 230 нчы аять).

*Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИННЫҢ җаваплары "Шура" журналының 8 нче санынннан алынды*

## БАЛАНЫ АНА КАРЫНЫНДА ЧАКТА УК ТӘРБИЯЛИ БАШЛАРГА КИРӘК



***Бала ата белән анага Аллаһы Тәгалә трафыннан бирелгән әманәт. Шушы бәһаләп бетергесез бүләк белән бергә аларга бала тәрбиясенә карата бурычлар да йөкләнә. Бу эш ана карынында чакта ук башлана:***

1) ир белән хатын никахта булырга тиеш;

2) ата белән ана хәләл ризык белән генә тукланырга тиеш.

Бик тәкъва ир белән хатынның җиде яшьлек бик тә тәрбиясез уллары булган. Урамга чыккач, ул бөтен кешегә зарар китереп йөри икән. Болар яши торган авыл корылыклы җирдә урнашканлыктан, халык суны ерактан арба белән балчык чүлмәкләрдә алып кайта торган була. Ә теге малай шул чүлмәкләрне таш бәреп ватып йөри ди. Тәкъва ата-ананы борчымаска тырышсалар да, су ташучыларның сабырлыгы бетә, көннәрдән бер көнне алар, малайның әтисенә килеп, барын да сөйләп бирәләр. Ата кеше тыңлап бетергәч, алардан улы өчен гафу үтенә. Аннары өенә кайтып, хатынына су ташучыларның зарларын сөйләп бирә һәм болай ди: "Мин үземнең кайчан да булса хәрам ризык ашаганымны хтерләмим, син дә исеңә төшереп кара әле, без нинди дер ялгышлык эшләмәдек микән?" Икенче көнне иртән хатыны ирен уятып: "Исемә төште! Йөкле чагымда мин күршеләргә кергәч, диварларына эленгән грушаларга күзем төште дә, кызыгып берсен тишеп, суын эчкән идем". "Улыбызның тәрбиясезлегенең сәбәбе менә шушы булырга мөмкин. Хәзер үк барып күршедән гафу үтен", - ди ире. Хатын күршесенә кереп оялып кына булган хәлне сөйләп бирә. Күрше хатыны аны кичерә. Шуннан соң малайның холкы да яхшы якка үзгәреп китә.

***Бала туганнан соң:***

1) балага матур исем кушарга кирәк;

2) ана баласын имезгәндә бисмиллә әйтергә һәм тәһарәтле булырга тиеш.

# СҮРИЯ, ЛИВИЯ, ЙӘМӘН: ХӘЛЛӘРЕ ШАКТЫЙ ЯМАН

**Ислам дөньясы тыныч түгел. Әллә инде, кайберәүләр расларга тырышканча, шеш тулып тишелгән дә, халык шуңа ярсый. Әллә читтән болгатырга теләүчеләр күп. Сүриядә, Ливиядә һаман күптән көтелгән тынычлык урнашмавы, Йәмәндә кан коела башлавы күңелсез фаразлар тудыра.**

Март ахырында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге ТР Диния нәзарәте делегациясе Сүрия башкаласы Дәмәшкъ шәһәрендә, мәшһүр мөселман галиме Мөхәммәт Сәет Рамазан әл-Бутыйның фаҗигале үлеменә ике ел тулу уңаеннан уздырылган җыелышта булып, байтак кына дәүләт һәм дин әһелләре белән күрешеп кайтты. Форсаттан файдаланып, делегация әгъзасы, мөфти урынбасары, РИИ ректоры, сәясәт фәннәре докторы Рәфикъ Мөхәммәтшинга мөрәҗәгать итеп, мөселман илләрендә барган хәл-вакыйгаларга аңлатма бирүен сорадык.

- Ике ел элек Рамазан әл-Бутыйны Дәмәшкъта, "Иман" дигән мәчеттә, шәкертләренә сабак биргән вакытта, бер җаһил керәп, шартлатып үтерә. Шул вакытта үзе белән бергә иң укымышлы, яраткан илле өч шәкерте дә шәһит китә. Безне шул хәзрәткә багышланган халыкара җыелышка чакырдылар. Сүриядә хәлләр шактый катлаулы. Дөрес, ике ел элек булган хәлләр белән чагыштырганда вазгыять тамырдан үзгәргән. Илдә берләшү омтылышы көчәйгән. Элек оппозиция бик көчле, Бәшәр Әсәдкә мөнәсәбәт шактый тискәре иде. Бу гаҗәп тә түгел: аны сектант дип исәплиләр, шигыйләргә караучы галәвиләрдән саныйлар иде. Мәгълүм ки, галәвиләрнең исламга мөнәсәбәте уңай түгел дигән караш киң таралган. Шуңа күрә илдә кан коела башлагач, дин әһелләре, зыялылар арасында Әсәдне яратып бетермәүчеләр күбәйгән иде. Әмма гражданнар сугышы барышында оппозициядәге көчләрнең Сүрияне таркатырга тырышуы ачык күренде. Инде бүген ил халкының Бәшәр Әсәдкә мөнәсәбәте уңай якка шактый үзгәргән. Әл-Бутый нәкъ менә дәүләтне берләштерүнең мөһимлеген, халык сайлап куйган кешеләргә буйсыну киреклеген әйтеп килгән иде. Бәшәр - халык тарафыннан сайланып куелган илбашы бит.



**- Сүриядә хөкүмәт гаскәрләренә һәм Әсәдне яклаучы Иран хәрбиләренә хәлифәлек корырга чакыручы ИГИЛ каршы торамы?**

- Хәзерге вакытта Сүриянең 40 процент җире оппозиция, ягъни ИГИЛ тарафдарлары кулында. Бер караганда, кырык дигәне шактый зур күренсә дә, төп сәнәгать үзәге булган шәһәрләр Әсәд карамагында. 40 процентның шактый өлеше - чүлле җирләр. Дөрес, хәзер хөкүмәт гаскәрләре Галеб (Алеппо), Хомс шәһәрләрен азат итеп килә.

**- Иран тарафы, Россия дә Әсәдне яклый дип беләбез.**

- Әлбәттә, Россия аны яклый. Якын Көнчыгышта хәзер безнең башка союздаш илләр калмады диярлек. Согуд Гарәбстаны, Катар, Кувәйт кебек илләр - Америка, Европа тарафдарлары, аларга икътисадый яктан тыгыз бәйле. СССР вакытында Көнчыгыш илләрендә тәэсиребез көчле иде. Мисыр, Сүрия, Ливия белән дә тыгыз хезмәттәшлек иткәнбез. Ливияне бик җиңел генә бирдек. Нәтиҗәдә, Муаммар Каддафины вәхшиләрчә үтерделәр. Ливия мисалы Россиягә зур сабак булды, шуңа күрә ул Сүриядә үз дигәнендә нык торды. Дөрес, хәлләр барыбер шактый катлаулы. Әйтик, Төркия баштан ук Әсәдкә нык каршы булды. Хәзер дә аны яратмый. Шул ук вакытта ИГИЛның җиңеп чыгып, үз чигендә радикал ислам дәүләте коруына риза булмаячак.

Гыйракта һәм аның кебек көчсезләнеп барган илдә - Сүриянең бер өлешендә ИГИЛ үз максатын тормышка ашырмакчы. Ни дәрәҗәдә дөрестер, ИГИЛны АКШ проекты дип тә әйтәләр. АКШка Көнчыгыш илләрендәге вәзгыятьне какшату, үз йогынтысын киңәйтү бик мөһим. Әмма хәзер ИГИЛ, бәйдән ычкынып, куркыныч бер көчкә әйләнде.

**- Йәмәндә дә хәлләр тыныч түгел бит әле. Илнең икегә бүленү куркынычы бар, хәтта Йәмән өчен Согудия белән Иран арасында сугыш чыгуы бар, диләр...**

- Әйе, Йәмәндә гражданнар сугышы башланып китте. Шунысы да куркыныч: Согудиянең инде күптән башка илләрне бомбага тотканы юк иде. Йәмәндә, күршесендә корал куллана башлады. Чынлап та, согудиялеләр Йәмән хөкүмәте башына шигыйләр килү ихтималына бик җитди карый. Йәмәндә барган процессклар, чынлап та, бик куркыныч. Анда бик нык коралланган кабиләләр бар. Ливиядә дә шундый кабиләләр шактый. Аларны бары тик Каддафи генә тотып, тыеп тора ала иде. Ливиядә барган гражданнар сугышы кабиләләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләргә дә бәйле.

Кыскасы, Йәмәндә согудиялеләр белән иранлыларның мәнфәгатьләре кисешә. Йәмән стратегик яктан бик яхшы урында, бугазда урнашкан. Әлеге бугаз аша Согудиянең бөтен корабы йөри. Согудиялеләр шушы өлешне эләктереп калмакчы, ахры. Азагы хәерле булсын: андагы хәлләр кабиләләр сугышына әверелеп китәргә мөмкин. Алай нык коралланган кабиләләр башка бер җирдә дә юк, диләр.



*Рәшит МИНҺАҖ,*
*"Ватаным Татарстан"*

***

Йәмән Җөмһүрияте Көньяк-Көнбатыш Азиядә, Гарәп ярымутравының көньягында урнашкан дәүләт. Якын Көнчыгышның бер өлеше булып тора, Оман һәм Согуд Гарәбстаны белән чиктәш. Чикләрен Кызыл диңгез һәм Гарәп диңгезе юа. Башкаласы Сәнга шәһәре дөньяның иң борынгы шәһәрләреннән санала. Бүгенге Йәмән - Төньяк һәм Көньяк Йәмән дәүләтләренең берләшүеннән килеп чыккан. Төньяк Йәмән 1918 елда ук Госманлы империясеннән бәйсезлек ала, ә Көньяк Йәмәннән исә инглизләр1967 елда гына китә. Йәмәндә 20 миллион кеше яши, шуларның яртысы - 15 яшен дә тутырмаган балалар. Халыкның 99 проценты мөселманнар. Йәмән җире берничә климатик зонадан тора. Диңгез ярларын биек тау сыртлары әйләндереп алган, ярымутрауның су чыганакларына бай, иң уңдырышлы җирләре Йәмәнгә туры килә.

Сәнгадагы зур мәчет ислам дөньясындагы иң мөһим гыйбадәтханәләрнең берсе. Уд Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында төзелгән, ислам тарихындагы өченче мәчет.

# Качаклар Европада сыену урыны эзли

Сүрия һәм Гыйракта барган кораллы бәрелешләр аркасында миллионлаган кеше чит илләрдә сыену урыны эзләргә мәҗбүр. БМО Югары комиссарының качаклар эшләре буенча идарәсе хәбәр иткәнчә, узган ел гына да тыныч илләргә күченергә теләп 866 000 гариза кергән. Бу сан Босния сугышының башлангыч чорындагыга караганда 45% ка күбрәк. Югары комиссар постын биләүче Антонио Гутерреш Еврокомиссиягә визитыннан соң болай дип белдергән: "Европаның качакларга куркынычсыз шартларда күчеп урнашуны тәкъдим итүе мөһим". Бу Сүрия һәм Гыйрак качакларын торак белән тәэмин итү, аларга гуманитар ярдәм күрсәтү, виза кагыйдәләрен йомшарту дигәнне аңлата.



# 4 яшьлек кыз бала интернетны "шартлатты"



Төрек фотографы фотога төшергән әлеге 4 яшьлек сүрияле кыз бала берничә сәгать эчендә бөтен дөньяда танылу алды. Ул фотограф кулындагы камераны корал дип белеп биреләргә уйлаган. Фотокорреспондент Осман Саджирли баланың мондый реакциясеннән тәмам югалып калган. "Ул бик курыккан иде, минем эре линзалы объективны күрүгә иреннәрен кысып кулларын өскә күтәрде. Гадәттә бит камераны күргән балалар оялалар, йөгереп китеп баралар яисә көләләр", - ди Осман. Кораллы кешене күрүгә үзеңне ничек тотарга өйрәнгән бу 4 яшьлек баланың ниләр кичергәнен чамалавы кыен түгел.

Фото Атмех дип аталган качаклар лагеренда төшерелгән.

# Дин тотучылар кайсы илдә күбрәк?



Җир йөзендә яшәүче халыкның өчтән икесе үзен дини дип саный икән. Газета.ру уткәргән тикшеренүләрдә 65 илдән барлыгы 64 000 гә якын кеше катнашкан. Нәтиҗәдә Тайланд – иң дини ил булып чыккан, андагы халыкның 94% "динне тотам" дип җавап биргән, 1% исә үзләрен дәһриләр дип белдергән. Рейтингның икенче баскычын 93% тавыш җыйган Әрмәнстан, Бангладеш, Грузия һәм Марокко били. Ә менә Нидерландта дин тотучылар барлык халыкның нибары 26% ын, Чехиядә - 23%, Япониядә - 13%, Швециядә - 19% һәм Кытайда 7% ны гына тәшкил итә икән.

Сораштыруда катнашучы россиялеләрнең исә 70% ы үзен дини дип саный, 18% ы дин тотмый, ә дәһриләр 5% ны тәшкил итә.

## ТР МДН "ТАТАР СҮЗЕ" МОБИЛЬ КУШЫМТАСЫН ТӘКЪДИМ ИТӘ







Android өчен "Татар сүзе" дип аталган махсус мобиль кушымта эшли башлады. ТР МДН тарафыннан эшләнгән бу кушымта кулланучыларын иске татар сүзләре белән таныштыра. Һәркөн автоматик рәвештә сезнең телефоныгызга яңа сүз килә һәм аңа кыскача аңлатма бирелә, Коръән һәм хәдисләрдә кулланылышы күрсәтелә. Шунысы мөһим, кушымта телефон интернет челтәренә тоташмаганда да эшли. Аны сез "Play Маркет"та таба аласыз. Якын арада мобиль кушымта IOS өчен дә барлыкка киләчәк.

## НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Таң беленә башлый | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә Намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.05.2015 | 00:46 | 02:31 | 04:01 | 12:00 | 16:52 | 19:21 | 21:44 |
| 02.05.2015 | 00:38 | 02:29 | 03:59 | 12:00 | 16:53 | 19:23 | 21:48 |
| 03.05.2015 | 00:29 | 02:27 | 03:57 | 12:00 | 16:54 | 19:25 | 21:53 |
| 04.05.2015 | 00:18 | 02:24 | 03:54 | 12:00 | 16:55 | 19:27 | 21:57 |
| 05.05.2015 | 00:02 | 02:22 | 03:52 | 12:00 | 16:56 | 19:29 | 20:59 |
| 06.05.2015 | 01:50 | 02:20 | 03:50 | 12:00 | 16:58 | 19:31 | 21:01 |
| 07.05.2015 | 01:48 | 02:18 | 03:48 | 12:00 | 16:59 | 19:32 | 21:02 |
| 08.05.2015 | 01:46 | 02:16 | 03:46 | 12:00 | 17:00 | 19:34 | 21:04 |
| 09.05.2015 | 01:44 | 02:14 | 03:44 | 12:00 | 17:01 | 19:36 | 21:06 |
| 10.05.2015 | 01:42 | 02:12 | 03:42 | 12:00 | 17:02 | 19:38 | 21:08 |
| 11.05.2015 | 01:40 | 02:10 | 03:40 | 12:00 | 17:03 | 19:40 | 21:10 |
| 12.05.2015 | 01:38 | 02:08 | 03:38 | 12:00 | 17:04 | 19:42 | 21:12 |
| 13.05.2015 | 01:36 | 02:06 | 03:36 | 12:00 | 17:06 | 19:44 | 21:14 |
| 14.05.2015 | 01:34 | 02:04 | 03:34 | 12:00 | 17:07 | 19:46 | 21:16 |
| 15.05.2015 | 01:32 | 02:02 | 03:32 | 12:00 | 17:08 | 19:48 | 21:18 |
| 16.05.2015 | 01:30 | 02:00 | 03:30 | 12:00 | 17:09 | 19:50 | 21:20 |
| 17.05.2015 | 01:29 | 01:59 | 03:29 | 12:00 | 17:10 | 19:51 | 21:21 |
| 18.05.2015 | 01:27 | 01:57 | 03:27 | 12:00 | 17:11 | 19:53 | 21:23 |
| 19.05.2015 | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 12:00 | 17:12 | 19:55 | 21:25 |
| 20.05.2015 | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 12:00 | 17:13 | 19:57 | 21:27 |
| 21.05.2015 | 01:22 | 01:52 | 03:22 | 12:00 | 17:14 | 19:58 | 21:28 |
| 22.05.2015 | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 12:00 | 17:15 | 20:00 | 21:30 |
| 23.05.2015 | 01:19 | 01:49 | 03:19 | 12:00 | 17:16 | 20:02 | 21:32 |
| 24.05.2015 | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 12:00 | 17:17 | 20:04 | 21:34 |
| 25.05.2015 | 01:16 | 01:46 | 03:16 | 12:00 | 17:17 | 20:05 | 21:35 |
| 26.05.2015 | 01:14 | 01:44 | 03:14 | 12:00 | 17:18 | 20:07 | 21:37 |
| 27.05.2015 | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 12:00 | 17:19 | 20:08 | 21:38 |
| 28.05.2015 | 01:12 | 01:42 | 03:12 | 12:00 | 17:20 | 20:10 | 21:40 |
| 29.05.2015 | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 12:00 | 17:21 | 20:11 | 21:41 |
| 30.05.2015 | 01:09 | 01:39 | 03:09 | 12:00 | 17:22 | 20:13 | 21:43 |
| 31.05.2015 | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 12:00 | 17:23 | 20:14 | 21:44 |




## "ХУЗУР" НӘШРИЯТ ЙОРТЫ ТӘКЪДИМ ИТӘ




Күптән түгел дөнья күргән китапларның берсе **"КЛАССИЧЕСКОЕ ИСЛАМСКОЕ СЕМЕЙНОЕ ПРАВО"** ("Ислам динендә гаилә хокукы нигезләре") дип атала. Китап авторы - тарих фәннәре кандидаты, ТР МДНнең Голәмалар шурасы әгъзасы, Казан ислам институты проректоры Рөстәм Нургалиев. Китапның татар телендәгесе дә басмага әзерләнә.

Әлеге хезмәттә гаилә мөнәсәбәтләренең барлык яклары искә алынган, материалны яхшырак аңлау өчен мисаллар китерелгән, абруйлы мөселман тәгълиматы мәктәпләре һәм зур галимнәр фикерләре файдаланылган. "Гаилә хокукы - мөселман хокукының иң әһәмиятле бүлекләреннән берсе, ул хәләл җефетләр, балалар, шулай ук гаиләнең бүтән әгъзалары арасында шәхси һәм милек мөнәсәбәтләрен тәртипкә китерә. Әлеге бүлекне өйрәнүнең әһәмиятен баш миенә операция ясаучы нейрохирург эшчәнлеге белән чагыштырып була: табиб хатасы аркасында авыру үлмәсә дә, мәңгегә инвалид булып калырга мөмкин. Монда да шулай ук: хаталы фикерләү яки әлеге бүлекне белмәү безне рухи яктан үтермәсә дә, гаилә мөнәсәбәтләре өлкәсендәге иң гади нәрсәләрне белмәү аркасында ясала торган хата үзгәртеп булмаслык нәтиҗәләргә китерергә мөмкин", - диелә китапта.

Китап киң даирә укучыларга - мөселман уку йортлары мөгаллимнәре һәм студентлары, мөселман кануннары буенча яшәргә теләүчеләр һәм исламда гаилә хокукы белән танышырга теләүчеләр өчен тәгаенләнгән. Уку әсбабы аңлаешлы тел белән язылган, кулланылган дини терминнарга өстәмә аңлатма бирелгән.




**"ХИДЖАБ" ("ХИҖАП")** дип аталган китапның авторы -Эльвира Садретдинова. Китапка төрле милләт, дин вәкилләренең хиҗап турындагы фикерләре тупланган. Шулай ук күп кенә хатын-кызлар үзләренең хиҗап бәйләү тарихлары белән уртаклаша. Хиҗап бәйләүгә карата хокукый, дини, фәлсәфи фикерләр китерелә, медицина күзлегеннән мисаллар урын алган.




**"ШУРА"** альманахының 8 нче санында танылган дин әһелләренең вәгазьләре, хәнәфи мәзһәбе өйрәтүләренә багышланган язмалар, мөфти фәтвалары, дини сорау-җаваплар урын алган. Шулай ук төрле дини чаралар уңаеннан язылган публицистик материаллар бар. Танылган татар дин галимнәре Садыйк Иманколый, Ризаэддин Фәхретдинов эшчәнлекләре белән танышырга мөмкин. Намазга кагылышлы хәдисләр, көн дә укыла торган догалар, намаз вакытлары урнаштырылган. Шулай ук "Әмәли" китабының 1913 елны Казанда нәшер ителгән нөсхәсенең фотокүчермәсе бастырылган. Бу әсәр шигъри юллар белән язылган һәм безне Имам Әбү Мансур Мәтуриди гакыйдәсе белән таныштыра. "Әмәли" китабының авторы - Фирганә өлкәсе Ош шәһәрендә туган мәшһүр галим Сираҗеддин Габделхәсән Гали бин Госман әл-Оши (һиҗри 569 ел). Кыска гына вакыт эчендә хәнәфиләр арасында бу әсәр мәшһүрлек ала һәм хәзерге көндә дә ул Хәнәфи мәзһәбе мәдрәсәләрендә өйрәнелә. Татар мәдрәсәләрендә бу китап уку-укыту программасына кертелгән һәм танылган галим Шәйхелислам әл-Хәмиди тарафыннан татар теленә дә тәрҗемә ителгән.

***"Хузур" нәшрият йорты чыгарган китапларны Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан махсус кибеттән, шулай ук нәшрият йортының Huzurshop.ru интернет-кибетендә сатып алырга була.***

## Хаҗ сәфәре бәяләре төште

**"ДУМ РТ ХАДЖ" доллар бәясе арту сәбәпле килеп чыккан кризиска каршы чаралар күрә. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, хаҗ оешмасы Согуд Гарәбстаны Корольлеге вәкилләре белән килешеп, изге сәфәр бәяләрен төшерүгә иреште. Нәтиҗәдә "Эконом" һәм "Тизләтелгән" программалары тәкъдим ителә.**

"Эконом" программасының бәясе - 3600$.

"ДУМ РТ ХАДЖ"ның "Эконом" программасы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) хаҗ гамәлләрен хәнәфи мәзһәбе буенча башкару;

2) укулар оештыру;

3) Мәккә шәһәрендә Әл-Хәрам мәчетеннән өч километрга кадәр аралыкта яшәүне тәэмин итү;

4) сәфәрнең дәвамлылыгы 20-25 көн;

5) Мәдинә шәһәрендә 2 көннән күбрәк яшәү;

6) медицина иминияте; беренче медицина ярдәме һәрвакыт хаҗилар белән янәшә;

7) 4-10 кешелек кунакханә бүлмәләре;

8) Мәдинә һәм Мәккә кунакханәләрендә көненә ике тапкыр туклану;

9) Мина һәм Гарәфә үзәнлекләрендә туклану;

10) кунакханәдә Согуд Гарәбстаны Корольлеге Хаҗ министрлыгы стандартларына туры килгән санузел;

11) һәр төркемдә җитәкче;

12) Согуд Гарәбстаны Корольлегендә транспорт чаралары белән тулысынча тәэмин ителеш;

13) Мәккә шәһәрендәге кунакханәдә чәй, каһвә тәүлек дәвамында;

14) 5 литр зәмзәм суы;

15) хаҗи комплекты: әдәбият, зур һәм кечкенә сумка, иссез сабын;




16) корбан чалу;

17) ир-атлар өчен ихрам;

18) Согуд Гарәбстаны Корольлегенең җирле SIM-карталары;

19) Истәлек бүләкләре: DVD-диск һәм фото-видеоматериаллар.

"Тизләтелгән" программаның бәясе - 4300$. "Эконом"нан төп аермалыклар:

- Мәккәдә - 11, Мәдинәдә 2 көннән күбрәк яшәү;
- яхшыртылган туклану;
- сувенирлар.

**"ДУМ РТ ХАДЖ" хезмәткәрләре белән түбәндәге телефон аша элемтәгә керергә һәм программалар хакында тулырак мәгълүмат алырга мөмкин: +7 (843) 524-92-10.**

***Адресы: 420021, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт.***

ДИН вә Мәгыйшәт
*Апрель саны, № 4 (237)*

**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
*420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27/*
**Электрон адрес:** *naubahar67@list.ru.*
**Телефон:** *+7 950 326 38 36*

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**;*
*"Хузур" нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;*
*ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе **Нияз САБИРОВ**;*
*Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ**;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе **Габдулла ӘДҺӘМОВ**.*

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** *Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
**Нәшир:** *"Хузур" нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в)*

*Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.*
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" ААҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды *(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)*.
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9054**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **25 нче апрель** көнне **19.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **18.00 сәгатьтә.**